Зәй һөнәрчеләре

Зәй районында кызлар кияү йортына бирнәләрен сандыкка тутырып килә икән. Туку станогында тукылган карават җәймәләре, идән паласлары аларда беркайчан да модадан чыкмаган. Ата-бабалардан калган һөнәрләр әле булса югалмаган, аларны дәвам итүчеләр биредә шактый.

9 БИТ

Автокресло: таләпләр һәм кагыйдәләр

Балаларны машинада йөртү кагыйдәләренә Татарстан Эчке эшләр министрлыгының Казан буенча ЮХИДИ бүлеге җитәкчесе, полиция подполковнигы Игорь Новиков аңлатма бирә.

5 БИТ

1990 ЕЛДАН БИРЛЕ ЧЫГА

Шәһри КАЗАН

татмедиа

Пәнҗешәмбе | 2.03.2017 | № 21 (5783)

www.shahrikazan.com

ТАТАРСТАН БАШКАЛАСЫНЫҢ КӨНДӘЛЕК ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ҺӘМ МӘДӘНИ ГАЗЕТАСЫ

ҺӘРКЕМ ӨЧЕН ҮЗ КЕШЕ

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановка – 60 яшь

Президент Рөстәм Миңнеханов Балык Бистәсе районының Яңа Арыш авылында туса да, биографиясе Саба районы белән тыгыз бәйләнгән. Мәктәп еллары, сыйныфташлар, укытучылар, төп нигез, беренче эш тәҗрибәсе – күп нәрсә нәкъ менә Сабага барып тоташа. «ШК» журналистлары Президентның балачак, яшьлек эзләре буйлап, аның туган ягында булып кайтты.



6-7 БИТ

Шамил Абдюшев, Дамир Бәдриев фотолары

Реклама

П2430 Атналык (пәнҗешәмбе)

1 айга 66 сум 99 тиен
3 айга 200 сум 97 тиен
6 айга 401 сум 94 тиен

Ташламалы бәядән язылып кал!

Һәр айның 15 числосына кадәр язылсагыз, газета киләсе ай башыннан киләчәк.

Синең өчен, синең турында!

П2395 Көндәлек (сишәмбе, пәнҗешәмбе, җомга)

136 сум 15 тиен 1 айга
408 сум 45 тиен 3 айга
816 сум 90 тиен 6 айга

РЕСПУБЛИКАДА

ӘЛМӘТ

Әлмәттә сыр фестивале узган. Сыр һәм башка натураль азык-төлек фестиваленең бередә беренче тапкыр узуы. Бу көнне әлмәтлеләр һәм кала кунаклары сырның төрле сортларыннан, шәхси җитештерүчеләрнең азык-төлекләреннән авыз иткәннәр. Моннан тыш, фестивальдә катнашучылар өчен сыр кайнату һәм кыздыру буенча осталык дәресләре үткәрелгән.

АПАС

Апас районы Заготзерно бистәсендә 2009 елдан бирле эшләп килүче «Нәҗиб» мәчетендә дини белем алучылар өчен барлык уңайлылыклар да булдырылган. Мәчет таләпләренә туры килерлек итеп яңа келәмнәр җәелгән. Шулай ук турыдан-туры 32 дини каналны карый торган антенна-приставка куелган, радио микрофон эшләп тора, дип яза район газетасы. «Нәҗиб» мәчете исеменнән «Ләйсән», «Гөлчәчәк» балалар бакчаларына, «Алтын алка» боз сараена келәмнәр дә бүләк ителгән.

ЧАЛЛЫ

Чаллыда йога күнегүләре белән шөгыльләнгәндә сигез яшьлек малай буылып үлгән. Бу хәл өйдә әти-әнисе юк чакта була. Әлеге гаилә инде берничә ел йога белән мавыга икән. Алар фатирларына йога күнегүләре өчен махсус үрмә аятклар урнаштырган булган. Малай мәнә шунда күнегүләр ясаганда буталган һәм азагы хәвефле беткән. Әти-әнисе кайткач, аны коткарырга тырышса да, инде соң була. Бу вакыйга буенча хокук саклау органнары тикшерү эше башлаган.

КУКМАРА

Кукмара балыкчылары Нократ Аланы шәһәрендә балык тоту буенча 1нче кышкы ачык турнирда җиңгән. Металл савыт-сабалар заводы хезмәткәре Рамил Ситдыйков гомуми нәтиҗәләр буенча чемпион исемен яулаган. Иң зур балык тотучыга билгеләнгән призга да Рамил лаек булган.

ТУКАЙ

Тукай районында милли ризыклар бәйрәме узган. Ул Сәмәкәй мәдәният йорты каршында эшләп килүче «Зиләйлүк» ансамбленең «Каз өмәсе күренеше» белән башланып киткән, ә Гөлфирә Әюпова тәбикмәк пешерү буенча остаханә үткәргән. Аннан соң, килгән кунаклар үз күчтәнәчләрен тәкъдим иткәннәр.

ЮТАЗЫ

Ютазы районы Алабакүл авылында яшәүче хезмәт ветераны Әнвәрия Вахитова шушы көннәрдә үзенең олуг юбилеен – 95 яшен бәйрәм иткән. Гомер буе балаларга белем биргән әбекәйне район җитәкчеләре дә тәбрикләгән.

Яңалыклар район газеталары сайтларыннан алынды.

Ана капиталы 2018 елга кадәр бирелә

Ана капиталы турындагы закон гамәлгә ашырыла башлаганга 10 ел булган. Бу уңайдан «Татар-информ» агентлыгында Россия Пенсия фондының Татарстандагы социаль түләүләр буенча бүлекчә җитәкчесе Гөлсинә Сабирова ана капиталына кагылышлы сорауларга җавап бирде.

Эльвира МОЗАФФАР

poliksal.ru

Ана капиталы барлыкка килгәннән бирле, республикада туучылар саны якынча 10 процентка арткан. Ун ел эчендә әлеге дәүләт сертификатын барлыгы 255 мең гаилә рәсмиләштергән.

– Ана капиталын берничә юнәлеш буенча: торак шартларын яхшырту, баланың укуы өчен түләү, ананың булачак пенсиясен арттыру максатларында файдаланырга була. 2015 елның ноябрендә кабул ителгән яңа Федераль закон буенча, ана капиталын куллануның яңа төре гамәлгә керде. Хәзер бу дәүләт ярдәмен инвалид балаларның җәмгыятькә интеграциясе һәм иҗтимагый адаптациясе өчен кулланылган товарлар һәм хезмәтләр сатып алуга тотарга да мөмкин, – диде Гөлсинә Сабирова.

Шул рәвешле, ана капиталын 160 мең гаилә торак шартларын яхшыртуга тоткан. 9 мең гариза, капиталны баланы укыту өчен кулланырга телим, дип тапшырылган. 47 ана акчаны булачак пенсиясенә күчерәчәген белдергән. Ә мәнә инвалид балаларга ярдәм күрсәтү юнәлеше буенча киңәш сорап килүчеләр булса да, әлегә ана капиталын бу максатларда файдаланучылар юк икән.

Ана капиталын алдау юлы белән алучыларга карата Пенсия фонды ныклы эш алып бара. Гөлсинә Сабирова сүзләренчә, чегәннәр арасында: «Икенче, өченче баламны таптым», – дип, ялган документлар нигезендә дәүләт сертификаты алырга теләүчеләр булган. «Мондый мөрәҗәгатьләр күбәйгәч, имеш, игезәкләр туу очраклары ешайгач, бу чегәннәр турында хокук саклау органнарына хәбәр иттек. Тикшерү нәтиҗәсендә аларга карата җинаять эше ачылды», – диде спикер.

Закон гамәлгә кергән беренче елларда ана капиталының суммасы 250 мең сум булса,ел саен индексацияләнеп, бүген ул 453 меңгә җиткән. Шунысы да бар, 2020 елга кадәр кабул ителгән закон нигезендә ул башка артмаячак. Ана капиталы программасы 2018 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә. Алга таба ул озайтылырмы – вакыт күрсәтер.

Россия Пенсия фондының сайтында шәхси кабинет аша электрон рәвештә мөрәҗәгать итү мөмкинлеге булдырылган. Ана капиталын рәсмиләштерү, файдалану, калган акчаны карау өчен дәүләт хезмәте порталыннан (gosuslugi.ru) файдаланырга була.

Шәһәр кәефе

ФӘРИТ ВӘЛИУЛЛИН,
рәссам-монументалист:

– Еш кына 60нчы елларда калган җылы, милли Казаныбызның юксынам. Казан милли, тарихи йөзен җуймаска тиеш. Безгә 2005 елны тимер юл вокзалы диварына Виктор Федоров һәм Сергей Бубенов ясаган «Совет Татарстаны» графитосы урынына нинди дә булса яңа эш ясарга яки шуны реставрацияләргә тәкъдим иттеләр. Аны юк итәргә кул күтәрелмәде. Рәшит Шиһабетдинов, Рәшит Тимереев белән тулысынча реставрацияләп чыктык. Моның белән бик горурланам.

МИННЕГӨЛ СӘГЫТДИНОВА,
төзүче:

– Үзем Азнакай районы Якый авылыннан. Институтны тәмамлагач, эшкә Ульяновск шәһәренә билгеләгәннәр иде. Шактый гомер туганнардан читтә үтте. Казан барыбер үзенә тартып кайтарды. Башта кызым Рәмилә үзем кайчандыр укыган институтка укырга керде. Аның артыннан гаиләбез белән үзебез дә күченеп кайттык. Казан – төзек, заманча, шул ук вакытта меңьеллык тарихы булган шәһәр. Балалар да үз татарым арасында бит хәзер, дип сөенеп яшим.

ХАЛИДӘ ИБРАҺИМОВА,
пенсионер:

– 1984 елдан бирле үземнең туган авылым Түнтәрдә татар теле укыттым. Гаиләдә дүрт бала тәрбияләп үстердек. Авыл кешесенә йорт-җирен ташлап Казанга чыгып китү гел эләкми. Бүген көнемне КФУның татар теле бүлегендә укыган чакларны барлауга багышладым. Тулай торакка да барып килдем, үзебез йөргән ашханәгә дә кереп чыктым. Кайберәүләр бәлкем мине аңламаслар да, әмма гомер узган саен, үткән елларның кадере тагын да арта икән.

ГӨЛНАЗ ШӘЙДУЛЛИНА,
декрет ялында:

– Казанның Левченко бистәсендә туып-үстем. Кияүгә чыкканнан соң, гаиләм белән Яңа Савин районында яши башладык. Әлеге вакытта ике бала белән өйдә. Кызыбыз Сабина балалар бакчасына йөри, улыбыз Азаматка – ике ай. Быелгы грипп безне дә читләтеп узмады. Гаиләдә барыбыз да авырдык. Аеруча балаларның авыруы озакка сузылды. Алар авыргач, әни кешегә бигрәк кыен. Шуңа күрә барыбызга да сәламәтлек телим.

АЙНУР ШӘРАПОВ,
студент:

– Ниһаять, яз җитте. Шуңа да кәефләр күтәренке, әмма күңелне бер нәрсә тырнап тора: юлларда машиналар бермә-бер артачак хәзер. Кыш буе «йоклаганнары» да чыгачак дигән сүз. Үзем дә машина йөрткәч, аварияләр турында ишетсәм, йөрәкләр «жу» итеп китә. Юлларда барыбызны да Ходай үзе сакласын, дип телим. Әтәч елының язы хәере белән килсен! Булган бар күңелсезлекләр кар сулары белән агып китсен иде.

АНА КАПИТАЛЫНА КАГЫЛЫШЛЫ 3 СОРАУ

Россия Пенсия фондының Татарстандагы социаль түләүләр буенча бүлекчә җитәкчесе **Гөлсинә САБИРОВА** җавап бирә:

1 Ана капиталын әти кеше алырга хаклымы?

– Әгәр әти икенче баласын уллыкка алган бердәнбер кеше икән, ул ана капиталына дәгъва кыла ала. Әлегә бер генә ир-атның да ана капиталын рәсмиләштергәне юк. Җырчы Филипп Киркоров бердәнбер бугай! Ә менә хатыны үлеп китеп, ана капиталыннан файдалану хокукы иренә күчкән очраклар бар.

2 Инвалид балалары булган ата-аналарга Ана капиталын ярдәм юнәлешендә файдаланырга була. Инвалид баланы йөртү өчен автомобиль алырга буламы?

– Инвалид балаларның җәмгыятькә интеграциясе һәм иҗтимагый адаптациясе өчен кулланылган товарлар һәм хезмәтләр исемлеге дәүләт тарафыннан расланган. Анда физик яктан мөмкинлеге чикле балаларга кирәкле техник чаралар, телевизор, компьютер кебек кирәк-яраклар кергән. Кызганычка, бу исемлектә автомобиль юк.

3 Элегрәк ана капиталының бер өлешен акчалата алу каралган иде. Быел бу мөмкинлек биреләчәкме?

– 2009 елдан бирле ана капиталыннан бер тапкыр бирелә торган түләүне алырга була иде. Былтыр да бу мөмкинлектән күп гаилә файдаланды. Гариза нигезендә ана капиталының 25 меңе акчалата бирелде. Бу программага быел да ихтыяҗ зур. Тик әлегә бу хакта закон кабул ителмәгән.

ФИФА Казаннан имтихан алды

Кичә ФИФА вәкилләре һәм «Россия-2018» оештыру комитеты «Казан-Арена» стадионында Футбол буенча дөнья чемпионатына барган әзерлек эшләре белән танышты.

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

«Россия-2018» оештыру комитеты генераль директоры Алексей Сорокин чемпионат буласы һәр шәһәрнең үз кимчелекләре барлыгын әйтеп узды.

– Инспекция вакытында без шәһәр һәм стадионнар торышын тикшерәбез. Бу – Конфедерация кубогы алдыннан соңгы тикшерү. Казан безгә яхшы таныш. Без монда Конфедерация кубогына җирәбә уйнаттык. «Казан-Арена» стадионы премьер-лига һәм Европа турнирларын кабул итәргә әзер. Конфедерация кубогы һәм дөнья чемпионаты шулкадәр катлаулы чаралар, тулысынча әзер бер генә стадион да юк әле. Чишелмәгән мәсьәләләр күп. Ләкин алар туктаусыз калырлык түгел. Бу проблемаларны хәл итү өчен, без монда җыелдык та инде, – диде Алексей Сорокин.

Ярышлар һәм чаралар оештыру буенча ФИФА департаменты директоры Колин Смит сүзләренчә, Конфедерация кубогы белән чемпионат искиткеч чаралар булачак.

– Кубок башланырга 108 көн калды. Бу стадион башка сыймаслык матч, искиткеч уен күрәчәк. Мин һәркемне монда килергә өндим. Сезнең барысын да үз күзегез белән күрер өчен кабатланмас мөмкинлек бар, – диде Колин Смит.

– Алдагы очрашуда әйтелгән бөтен кимчелекләрне бетерергә тырыштык. Җирәбә салу вакытында безгә бәхет елмайды – иң яхшы командалар безгә киләчәк. Спортчылар өчен футбол кырын гына түгел, ә шәһәрне дә уңайлы итеп ясарга тырышабыз, – диде Татарстанның яшьләр эшләре һәм спорт министры Владимир Леонов.

Алисә САБИРОВА.

БИЛЕТЛАР САТУДА

Сүз уңаеннан, 1-5 март көнне Конфедерация кубогына билет сатуның икенче дулкыны башланды. Футбол матчын карау өчен, www.fan-id.ru сайты аша гариза тутырып, «җанатар паспорты»н алырга кирәк. Билетларны Халыкара футбол федерациясе сайтында сатып алып була.

Билетлар дүрт категориядә. Стадионда иң яхшы урыннар – I категорияле. IV категория бары Россия гражданнары өчен генә каралган. Ул халык өчен кулай бәядән булачак. Калган урыннар II-III категориягә керә. Мөмкинлекләре чикле кешеләр өчен аерым урыннар каралган.

Билет сатуның соңгы этабы 19 апрель-2 июль көннәрендә булачак.

Исегезгә төшерәбез, Конфедерация кубогы Мәскәү, Санкт-Петербург, Казан һәм Сочи шәһәрләрендә уза. Казанда дүрт матч көтелә:

– 18 июнь, 18:00 сәгатьтә Португалия – Мексика;

– 22 июнь 21:00 сәгатьтә Германия – Чили;

– 24 июнь 18:00 сәгатьтә Мексика – Россия;

– 28 июнь 21.00 сәгатьтә А1 һәм В1 категорияләре җиңүчеләре арасында ярымфинал.

Барлык уеннар да «Казан-Арена» стадионында узачак.

Күпләр «Татфондбанк»ны санацияләү белән кызыксына. Март аенда бу мәсьәләгә ачыклык кертелергә тиеш, дип вәгъдә итәләр.

ТАИФ «Татфондбанк»ка ярдәм итәргә әзер

Президент Рөстәм Миңнеханов та әлеге мәсьәләгә үз аңлатмасын бирде: «Хәзер без бер төркемебезне тәкъдим иттек – ТАИФ һәм аның партнерлары. Үзәк банк бу сорауны карый. «Татфондбанк»тан зыян күргән клиентларга, ярдәм йөзеннән яңадан кредит алу мөмкинлеге тудырып, 1 миллиард сум акча бүлеп бирелде. Дөрес, бу барлык проблеманы да чишә дигән сүз түгел».

Баксаң, ТАИФ һәм аның партнерыннан тыш санациягә башка структуралар да дәгъва белдергән. Әмма Үзәк банк аларны кабул итмәгән. Бу әлеге оешмаларның кредит тарихына һәм актив сыйфатына да бәйле. Бу арада, полиция хезмәткәрләре Мәскәү өлкәсендә «Татфондбанк» җәмгыяте идарә рәисе урынбасары Сергей Мещановны тоткарлаган, дип хәбәр итә Татарстан Эчке эшләр министрлыгы матбугат хезмәте. Сергей Мещанов банк белән бәйле акча урлауда шикләнелә. 18 февральдә федераль эзләүгә бирелгән иде. Хәзер ул Казанга кайтарылган. Тикшерү эшләре дәвам итә.

«Татфондбанк»ның 142 меңнән артык кертемчесе имиништләштерү агентлыгы аша акчаларын кире кайтарган. Февральнең соңгы көненә алынган мәгълүматлар буенча, кертем түләүләренең гомуми суммасы 43,1 миллиард сумны тәшкил итә. Барлык сумманың 93,1 проценты түләнгән. «Интехбанк» клиентлары исә 12,4 миллиард сум акчаларын кайтара алганнар. Хәзерге вакытта барлык сумманың 97,3 проценты түләнгән.

tatarstan.ru

Яңа тапшырылган машиналарның 11е – Ford Transit, 40ы – ГАЗ-322121.

Хәерле юл!

Кичә Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов район җитәкчеләренә өр-яңа мәктәп автобуслары ачкычлары тапшырды.

Президент сүзләренчә, бүген мәктәп автобуслары – алыштыргысыз транспорт. Бала теләсә кайсы авыл җирлегендә яшәсә дә, шәһәрдәге кебек, белем алу мөмкинлекләре булырга тиеш бит.

– Без бөтен җирдә дә база мәктәпләре ача алмыйбыз. Мәктәп автобуслары авыллардан балаларны зуррак мәктәпләргә илтергә ярдәм итә, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Республика җитәкчесе шулай ук, мәктәптә белем бирүгә кагылышлы программаларны хуплаган өчен, Россия Федерациясе җитәкчеләренә рәхмәт сүзләре җиткерде. Бүген тапшырылган 51 машина да федераль программа нигезендә алынган. Узган елны исә авыл мәктәпләре өчен 100 автобус кайтартылган.

– Мәктәп автобуслары программасы алга таба да дәвам итәчәк. Без бу автобусларның маршрутларын да җентекләп күзәтәбез. Балаларны закон таләбе буенча йөртегез. Иң мөһиме – куркынычсызлык. Мәктәп автобуслары, бала кайда яшәвенә карамастан, сыйфатлы белем алуга бер адым булыр дип ышанам, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Шулай итеп, кичә Әгерҗе, Әтнә, Балтач, Буа, Биектау, Мөслим, Түбән Кама, Яңа Чишмә, Питрәч h.б. 26 район мәктәпләре яңа автобуслы булды.

ҮТЕП БАРЫШЛЫЙ

Равил САБЫР

«Үлде инде ул...»

Бүген булмаса, иртәгә бакыйлыкка күчәргә тиешле бер карт әйткән иде бу сүзләрне. Хәлен белергә дип килгән идек без ул көнне аның янына. Мөнәвир абый бик нык авырый икән дигәч, биш кеше машинага төялдек тә киттек. Утырабыз шулай ул үлем көтеп яткан бүлмәдә, тегесе-монысы турында сөйләшәбез, үткәннәрне искә алабыз, кызык-мызык хәлләр дә хәтердә яңара.

Шулай сүз иярә сүз чыгып, Мөнәвир абый сөяркә турында ниндидер бер мәзәк сөйләде.

Хәләл җефетенә шул җитә калды:

— И-и-их, беләсе иде дә бит синең нинди хатын белән чуалганыңны, бер барып күзләренә карыйсы иде дә шуның, әйтмисең инде син аны, үзең белән теге дөньяга алып китәсең сереңне, — ди.

Үзе безнең якка карап күз кыса.

Менә шунда Мөнәвир абый теге сүзне әйтте:

— Үлде инде ул...

Имеш, барыбер барып күзләренә карый алмыйсың. Хатыны төпченә торгач, серенең калган өлешен дә ачып бирде: ир урталары чагында күрше урыс авылындагы бер марҗа янына барып йөргәләгән икән.

Үзе дә урыс авылында яши иде Мөнәвир абый.

— Сине монда нинди җилләр китереп ташлады соң? — дип сораган идем мин аннан берсендә.

— Әтине утерделәр минем монда, — дигән иде Мөнәвир абый. — Урманга киткән җирдән кайтмады. Икенче көнне гәүдәсен шушы авылда тапканнар. Кем үтергәнен милиция ачыклый алмады. Үзем барыбер табам, дип килеп урнашкан идем яшь чакта, тәки гомер буена берни белә алмадым...

Өч баласы да шушында туып-үскән Мөнәвир абыйның. Уллары марҗага өйләнгән, кызы урыска кияүгә чыккан, оныкларының исеме кайсыныкы татарча, тик күбесе урысча. Татар исемле оныклары белән дә урысча сөйләшә иде Мөнәвир абый.

Менә хәзер аның турында сөйләгәндә, ул үзе теге юлы әйткән сүзләрне кабатларга туры килә: үлде инде ул...

Җүнсез хәбәр яшен тизлегендә тарала бит ул. Теге чактагы сыман машинага төялдек тә Мөнәвир абыйны җирләргә киттек. Без килеп әллә ни вакыт та узмады, аның гәүдәсен йортыннан күтәреп алып та чыктылар. Мин аны-моны аңлаганчы-абайлаганчы, халык тезелешеп урам буйлап зиратка таба атлый да башлады. Иң алда — тактадан ясалган тәре. Алай дисәң, тәре дә түгел ул үзе, чөнки иң өстендә — ярымай.

Бер олырак абзыйга: «Нәрсә соң инде бу?!» — дип сүз каткан идем, ул: «Тавышланма, аларда тәртибе шундый инде», — диде.

Зиратта тезелеп киткән тәреләр арасында кабер казыганнар Мөнәвир абыйга, ләхет алып тормаганнар... Мулла юк та юк инде монда, Коръән уку да юк, гүр сәдакасы да юк, безнеңчә берни дә юк, барысы да ят...

Зираттан Мөнәвир абыйның йортына кире кайтсак, ишегалдына өстәл әзерләгәннәр, хәзер поминка буласы икән...

Бу хәлләр күптән, берничә ел элек булып узса да, гел баштан чыкмый. Онытылды инде дигәндә генә тагын искә төшеп, күңелне үрсәләндереп тора. Менә аптырагач, кәгазьгә яздым...

Бу дөньядан кешечә китәр өчен кешечә яшәргә дә кирәк шул — үзебезчә, ата-бабаларча, борынгыдан килгән гореф-гадәтләрне, яшәү рәвешен саклап. Үлем көтеп ятканда уйлады микән Мөнәвир абый үзен ничек соңгы юлга озатасыларын? Борчылды микән шул хакта? Әллә инде гомер буе чит кавем арасында яшәп шулай дөрес дип буталды микән? Ни кызганыч, бу турыда Мөнәвир абыйдан сорап булмый шул. Үлде инде ул...

МИЛЛИЯТ

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

Казанда узачак VI Бөтенроссия татар авыллары эшмәкәрләре җыенын Татар эшмәкәрләре ассоциациясе җитәкчесе Фәрит Уразаев милләтләр җыены дип атый. «Авылларга йөкләнгән төп миссияләрнең берсе – милләтне саклап калу», – ди ул. Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитетында 9-11 мартта Казанда узачак әлеге зур чара хакында сөйләштеләр.

Авылларның төп миссиясе – милләтне саклау

Эльвира МОЗАФФАР

Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты рәисе урынбасары Марс Тукаев әйтүенчә, ел саен җыенның географиясе киңәя, катнашучылар саны арта. Быел Россиянең 40тан артык төбәгеннән, шулай ук Татарстан районнарыннан 700 кече бизнес вәкилләре һәм фермер хуҗалыклары җитәкчеләре бергә җыелыр дип көтелә. Бу җыенга хәтта чит илләрдән: Казахстан, Кытайдан да килергә теләк белдерүчеләр булган.

Җыенда төрле темаларга: игенчелек,терлекчелек һәм агросәнәгать комплексы продукциясен экспортлау, һөнәрчелек турында сөйләшәчәкләр, дискуссия мәйданчылары эшләячәк, мәдәни чаралар узачак. Делегатларны авыл эшмәкәрләренең хуҗалыклары һәм татар авылларының комплекслы үсеше белән таныштыру өчен Балтач, Арча районнарына алып барачаклар. 11 март көнне пленар утырышта Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановның катнашуы да көтелә. «Корстон» сәүдә-күңел ачу комплексында Россия төбәкләрендә җитештерелгән продукция һәм халык кәсебе товарлары күргәзмә-ярминкәсе эшләячәк. Шулай ук «Бөтенроссия татар авыллары» иҗтимагый оешмасы советының утырышы узачак.

Җыен барышында үзара тәҗрибә уртаклашканда, эшмәкәрләр икътисад, авыл хуҗалыгы турында гына түгел, милләтне саклап калу, тарихны барлау, социаль чаралар турында да фикер алышалар. Чөнки аларның күбесе – үз авылында лидер – мәктәпләр төзетүче, мәчетләр салдыручы, төрле чаралар оештыручы. Әйтик, быелтыр Башкортстаннан килгән эшмәкәрләр кызыклы гына проект тәкъдим иткән: Ык буенда урнашкан татар авылларының Сабан туен уздырырга. Быел, аларның проектлары хупланып, 22 июльдә Башкортстан Республикасының Туймазы районы Түбәнәк авылында Ык буе авыллары Сабан туе узачак. Билгеле булганча, Ык елгасы Башкортстан, Татарстан, Оренбургның барлыгы 14 районы аша уза. Бу Сабан туе Ык буе татар авылларының зур бәйрәменә әверелер дип уйлый оештыручылар.

Россиядә 4300ләп татар авылы исәпләнә. «Тәҗрибә күрсәткәнчә, ашлык җитештерүнең 50-80 проценты нәкъ менә шәхси хуҗалыкларга туры килә. Бу – татарларда традицион күренеш. Халыкларның яшәешен, мәдәни үсешен шушы шәхесләр формалаштырачак. Кызганыч, кайбер авыллар бүген картлар йортын хәтерләтә. Анда яшәүчеләрнең 70-80 проценты – пенсионерлар. Тагын 10-15 елдан авылларның киләчәге булырмы?» – дип борчыла Фәрит Уразаев. Авылларны саклап калуда, милләтне берләштерү юнәлешендә бу җыенның роле зур, дип саный ул.

ХЕЗМӘТЕНӘ – ХӨРМӘТЕ

«Шәһри Казан» хат ташучыларны ял иттерә

Газетабызны халыкка таратучы, танытучы чын дусларыбыз – почта хезмәткәрләре. Һәр авылның хат ташучысы психолог та, юрист та, кирәк икән – шәфкать туташы, сердәшче, киңәшче дә.

Без аларның хезмәтләренең бик җаваплы икәнлеген аңлыйбыз, хезмәт хакларының да зур түгеллеген беләбез. 2017 елның беренче ярты еллыгына язылу кысаларында «Шәһри Казан» газетасы район почта бүлекчәләре һәм хат ташучылар арасында бәйге игълан иткән иде. Җиңүчегә бүләккә «Волга» шифаханәсенә ике кешегә ун көнлек юллама вәгъдә иттек.

Нәтиҗә ясар чак җитте, бүгенге көндә «Шәһри Казан» газетасын иң күп укучы район – Арча. Районара почта бүлекчәсе җитәкчесе Ирек Фәйзрахмановка юлламаны тапшырдык.

Балтач районының Арбор авылы почта бүлекчәсе хат ташучысы Чулпан Әүхәдиева берүзе – 63 данә, Арчадан Гөлшат Габдрахманова 53 данә газетага яздырган. Аларга бүләккә хат ташучы сумкалары бирелде.

Ә газетага язылу дәвам итә. 2017 елның беренче ярты еллыгына язылу нәтиҗәләре буенча шулай ук саллы бүләкләр каралган. Бергә булыйк!

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

Киләсе тема коммуналь хезмәтләргә түләгәндә дәүләттән халыкка бирелә торган ташламалар турында булачак. Субсидияләрне рәсмиләштерүгә кагылышлы сорауларыгызны **(843) 562-50-03, 8(917) 851-69-62** телефоннары аша редакциябезгә юллый аласыз.

АВТОКРЕСЛО: таләпләр һәм кагыйдәләр

Яңа елдан гамәлгә кергән кагыйдәләр буенча, имеш, җиде яшьтән соң балаларны автомобильдә махсус креслосыз да йөртергә ярый дигән хәбәр халык арасында тиз таралды. Редакциягә дә бу хакта еш сорап шалтыраталар. Укучыларыбызның сорауларын истә тотып, Татарстан Эчке эшләр министрлыгының Казан буенча ЮХИДИ бүлеге җитәкчесе, полиция подполковнигы Игорь НОВИКОВ белән балаларны машинада йөртү кагыйдәләре турында сөйләштек.

Эльвира МОЗАФФАР

Яңа елдан җиде яшьтән зуррак балаларга машинада барганда автокресло кирәкми, дип ишеткән идек. Әмма күптән түгел генә ЮХИДИ хезмәткәрләре 10 яшьлек балабызны креслосыз йөрткән өчен штраф салды. Ачыклык кертсәгез иде.

Электрон почта аша килгән сорау.

Хәзерге вакытта Россия территориясендә 1993 елның 23 октябреннән кабул ителгән (№1090) юл йөрү кагыйдәләре гамәлдә. Кайбер пунктларына Россия хакимияте тарафыннан төзәтмәләр кертелгән. Соңгы үзгәрешләр буенча, юл йөрү кагыйдәләренең 22.9нчы пункты нигезендә, балаларны машинада йөрткәндә куркынычсызлык таләпләре транспорт чарасының конструкция үзенчәлекләренә бәйле рәвештә үтәлергә тиеш. Әлеге үзенчәлекләр исә автомобильдән файдалану кулланмасында күрсәтелгән. Гади итеп әйткәндә, машина үзебездә җитештерелгәнме, чит илнекеме – балаларның куркынычсызлыгын тәэмин итү максатларында, махсус утыргычлардан файдалану мәҗбүри. Баланы җиде яшьтән соң автокреслосыз йөртергә ярый дигән хәбәр дөреслеккә туры килми. Юл йөрү кагыйдәләренә бу хакта төзәтмәләр кертелмәде.

Яңа гына балабыз туды. Кечкенә сабыйларны машинада йөртүнең аерым кагыйдәләре бармы?

Азалия ФАРУКШИНА,
Казан.

2015 елның гыйнварыннан Таможня берләшмәсенең техник регламенты таләпләре буенча, балаларны йөртә торган утыргычларга сертификатлар бирелә. Моның өчен алар махсус сынаулар узарга тиеш. Тикшерүләрне уңышлы узган җайланмаларга гына Европа стандартлары буенча куркынычсызлык билгесе куела. Һәр җайланмага ул ничә килолы балага исәпләнгән, аны салонда ничек урнаштырырга кирәклеге турында мәгълүмат бирелә. Бик кечкенә сабыйлар өчен автобишекләр каралган. Алар 0, 0+ төркеменә керә. Бу бишекләрнең машинадан чыккач та үзең белән йөртү өчен махсус тоткычлары була, җайланманың ян-яклары да куркынычсызлык ягыннан көчәйтелеп эшләнгән. Бишектә бала юрганда төрелгән килеш түгел, комбинезонда булырга тиеш. Бу куркынычсызлык каешын эләктерү өчен кирәк.

Баланы ничә яшьтән алгы утыргычка утыртырга ярый? Үзем рульдә барганда, баланың нәрсә белән шөгыльләнгәнен күзәтеп бару миңа җайлырак.

Диана,
Казан.

Махсус җайланма кулланылганда, теория буенча, теләсә ничә яшьтән дә алгы рәткә утырту рөхсәт ителә. Креслоны машина салонында кайсы урынга урнаштыру турында да таләп юк. Шулай да кайбер кагыйдәләрне истә тотарга кирәк: машинаның алгы рәтендә 12 яшькә кадәрге бала утырып бара икән, автомобильдәге куркынычсызлык мендәрләрен сүндерергә кирәк. Бу юл һәлакәте булып, бәрелү вакытында куркынычсызлык мендәрләре яшь пассажирга зыян китермәсен өчен эшләнә. Краш-тестлар нәтиҗәсендә ачыкланганча, бала өчен салонда иң куркынычсыз урын – машинаның арткы рәттәге урта өлеше.

Улыма – 10 яшь. Ә авырлыгы – 41 кило. Мин аңа автокреслоны ничек сайларга тиеш?

Римма САФИУЛЛИНА,
Казан.

Иң мөһиме – автокреслоны бары махсуслашкан кибеттән, баланы утыртып карап кына алырга киңәш ителә. Бик зур авырлыктагы балалар өчен 36+ дигән аерым төркем креслолар да бар.

Балабызның буе бик озын: 150 сантиметр. 12 яше әле тулып өлгермәгән. Ул креслога утырса, башы машина түбәсенә тия. Безнең очракта куркынычсызлык каешлары белән генә чикләнергә ярыймы?

Исемем редакция өчен генә.

Әйе, чынлап та, 146 сантиметрдан узганнарга куркынычсызлык каешын эләктереп кенә дә йөрергә ярый. Әгәр баланың антропометрик параметрлары туры килә икән, аны махсус җайланмасыз да йөртергә була.

Безнең гаиләдә өч бала. Җиңел машинаның арткы утыргычына өч кресло берьюлы сыймый. Безгә нинди киңәш бирәсез? Биш-алты балалы гаиләләр дә бар. Бу очракта нишләргә?

Вафиннар гаиләсе,
Яшел Үзән.

Стандарт җиңел машина, гадәттә, биш кеше сыешлы була. Шул рәвешле биш кешелек гаилә машинага сыя ала, салонда иркенрәк булсын өчен, бер креслоны алгы рәткә куярга да мөмкин. Әгәр җиңел машинага биш кешедән артыграк пассажир утырган икән, балаларны, олыларны – анысы мөһим түгел, бу – юл йөрү кагыйдәләрен бозу булып санала. Киңәшем шул: йә күбрәк кеше сыйдырышлы машина сатып алырга кирәк, йә балаларны берничә рейс ясап, кирәкле урынга алып барырга. Җәмәгать транспортыннан, таксидан файдаланырга да мөмкин.

Автокресло урынына каты мендәр формасында эшләнелгән махсус җайланмалар куллану рөхсәт ителәме? Каешка каптырыла торган ФЭСТлар ышанычлымы?

Миләүшә ВАФИНА,
Саба районы.

2011елның декабрендә Юл куркынычсызлыгы Европа ассоциациясенең 50нче конференциясендә кайбер җайланмаларны сынап караганнар. Каешка беркетелә торган адаптерлар, артсыз утыргыч җайланмалар куркынычсызлык ягыннан үзләрен акламаган. Шуңа да белгечләр, кат-кат тикшергәннән соң, аларны балаларны машинада йөртү җайланмалары исемлегенә бөтенләй кертмәскә тәкъдим иткән. Бәйсез тикшерүләр вакытында ФЭСТ, ДАК (каркассыз креслолар) шулай ук түбән нәтиҗәләр күрсәткән. Әлеге сынау нәтиҗәләренә ышаныргамы, юкмы – һәрбер ата-ана үзе хәл итә. Фәнни тикшерүләр күрсәткәнчә, автокреслолар юл һәлакәтләре вакытында сабыйлар арасында үлем очракларын 80 процентка кадәр киметә. Куркынычсызлык каешлары исә бу яктан күпкә калыша.

Зуррак яшьтәге балаларны машинада йөртү өчен бустерлар кулланыла. Бустер – баланың буен «үстерә» торган каты мендәр рәвешендәге җайланма. Аны кулланганда, куркынычсызлык каешының бала гәүдәсе аша дөрес узуы мөһим. Мондый җайланмалар алты-җиде яшьлек һәм аннан да зуррак балаларга исәпләнгән.

Баланы автокреслосыз йөрткән өчен нинди штраф каралган?

Россия Федерациясе юл йөрү кагыйдәсенең 22.9нчы пунктын бозган өчен, 12.23нче маддәнең 3нче бүлеге нигезендә, (КоАП) 3 мең сум штраф каралган.

АВТОКРЕСЛО САЙЛАУ ТӘРТИБЕ

Төркем исеме	Баланың авырлыгы	Якынча яше	Креслоны салонда урнаштыру ысулы
0 төркеме	10 кг дан азрак	туганнан алып 6 айга кадәр	кресло машина хәрәкәтенә яны белән
0+ төркеме	13 кг дан азрак	туганнан алып 1 яшькә кадәр	машина хәрәкәтенә каршы
I төркем	9-18 кг	9 айдан 4 яшькә кадәр	хәрәкәт уңаена
II төркем	15-25 кг	3-7 яшь	хәрәкәт уңаена
III төркем	22 кг	6-12 яшь	хәрәкәт уңаена

Президент Рөстәм Миңнеханов Балык Бистәсе районының Яңа Арыш авылында туса да, биографиясе Саба районы белән тыгыз бәйләнгән. Мәктәп еллары, сыйныфташлар, укытучылар, төп нигез, беренче эш тәҗрибәсе – күп нәрсә нәкъ менә Сабага барып тоташа. «ШК» журналистлары Президентның балачак, яшьлек эзләре буйлап, аның туган ягында булып кайтты.

Илдар Мөхәммәтҗанов фотолары

ҺӘРКЕМ ӨЧЕН

Татарстан Президенты Рөстәм

Эльвира МОЗАФФАР

ПРЕЗИДЕНТ ТОРГАН АВЫЛ

Лесхоз бистәсе Мишә авыл җирлегенә керә. Биредә 1099 кеше исәпләнә. Бистә төзек, матур, юлларга асфальт салынган. Авылда спорт комплексы, өлкәннәр йорты бар. Әллә кайдан биек манаралы кызыл таш мәчет балкып тора. Ике катлы мәһабәт агач бина ерактан үзенә җәлеп итә. Бу – Саба урман хуҗалыгы тарихы музее. Саба урманчылыгы Татарстанның сигез административ районында барлыгы 61 мең гектар мәйданны били. Лесхозны еш кына урман эчендәге авыл дип тә йөртәләр. Тирә-юньне агачлар әйләндереп алган. Бистәдә заманча агач эшкәртү комплексы эшләп килә. Сувенир цехында әзерләнгән куна такталары, кашыклар, башка эшләнмәләр Татарстаннан читтә дә дан тота. Лесхозда «Урман» дигән су җитештерәләр, орлык эшкәртү белән дә шөгыльләнәләр. Авылда казлар, күркәләр, мал-туар үрчетүче фермерлар да җитәрлек. Тормыш гөрли, монда тырыш, бердәм халык яши.

Миңнехановлар гаиләсе авылга 1960 еллар башында күченеп килә. Ул чакта Нургали ага белән Васига ханымның төпчек уллары Рәис тумаган була әле. Васига ханым озак еллар балалар бакчасында тәрбияче булып эшли, Нургали ага 30 елдан артык гомерен урман хуҗалыгына багышлый. Миңнехановлар гаиләсе авылда зур хөрмәткә ия. Васига ханым – барысы өчен дә сабыр, акыллы үрнәк хатын-кыз, Нургали аганың абруе бөтен республикага билгеле. Ел саен авылда аның рухына дога кылалар, каберенә чәчәкләр салалар. Бу чарага еш кына Миңнехановлар гаиләләре белән җыелышып кайта. Авылда күп нәрсә Нургали ага исеме белән бәйле. Саба урман хуҗалыгында аның истәлегенә бюст куйганнар. Нургали исемен йөрткән урам да бар. Музейда да аның белән бәйле истәлекле экспонатлар күп. Беренче транспорты – «Урал» мотоциклы, тәүге кесә телефоны, яратып уйнаган шахматлары да биредә саклана. Музей түрендә урман хуҗалыгының символы – агач ябалак тора. «Сабалылар ябалак кебек төнлә дә йокламый, эшчән халык, дигәнне аңлата бу», – ди музей җитәкчесе Рузия Газизуллина, уенын-чынын бергә кушып.

Васига ханым үзенең төпчек улы гаиләсе белән бүген Лесхоз авылында гомер кичерә. Президентны исә авылдашлары, беренче чиратта, якташы, үз кеше итеп кабул итә, аның шундый зур дәрәҗәгә ирешүе белән горурлана, гади, ихлас булуына соклана.

КЫҢГЫРАУЛЫ МӘКТӘП ЕЛЛАРЫ

1963 ел. Беренче сыйныфка укырга кергәндә, Рөстәм Миңнехановка әле җиде яшь тә тулмаган була. Иптәшләреннән калдырасы килмичә, әти-әниләре улларын мәктәпкә иртәрәк бирәләр. Хәер, малай үзе дә кечкенәдән укырга хирыс була.

– Рөстәм – кыска гына буйлы, чандыр гәүдәле, укытучының сөйләгәннәрен түгәрәк зур күзләрен тутырып, сабыр гына тыңлап утырган укучым булып истә калган. Тыйнак, басынкы иде ул. Шул ук вакытта үҗәт, тырыш, сәләтле булды. Белмәгәнен белергә омтылды, гел беренче булырга атлыгып тора иде. Бер иптәше дәрескә килми калса, өенә кайтканчы, сыйныфташының хәлен белергә бара. Кечкенәдән әнә шундый кешелекле, дус җанлы иде. Бу сыйфатларын бүген дә саклап кала алган, дип сөенәм. Кечкенә чагында ук аның дәрәҗәле кеше булачагына ышандым, – ди беренче укытучысы **Римма Закирҗанова.**

Башлангычтан Рөстәм Миңнехановлар классын **Фәгыйлә Талипова** кабул итеп ала. 82 яшен тутырган Фәгыйлә Фазлый кызының яраткан укучысы турында сөйләр сүзләре җитәрлек.

– Класслары белән бик акыллы, тәртипле иде алар. Тату, дус булдык. 22 бала бердәм булып укыды. Укытучыларны бик хөрмәт иттеләр. Шөкер, тормышта берсе дә югалып калмады. Мин аларны математикадан да укыттым әле. Рөстәмгә чут төймәләрен тартырга мин өйрәттем инде, – дип көлә укытучы. – Әтисе Нургали ага ата-аналар җыелышына даими килә иде.

«Барыбыздан да олы булды»

*Рөстәм Миңнехановның сыйныфташы **Фәния Латыйпова** (27 ел Саба районы хакимиятенең статистика бүлегендә хезмәт иткән):*

– Рөстәм белән балалар бакчасыннан бирле таныш без. 1963 елда беренче сыйныфка бергә бардык. 22 укучы идек. Лесхоз мәктәбен тәмамлаганнан соң, Сабага 19 бала укырга килдек. Үзебез тулы бер класс диярлек. Ул вакытта балалар күп иде. Без «Е» классы булып укыдык. Балачакта барыбыз да бертөсле булдык инде. Физкультура дәресен бик яраттык. Малайларга каршы без – кызлар, футбол уйный идек. Хәзер дә дартс уенында актив катнашам, ату буенча ярышларга йөрим әле. Башлангыч сыйныфларда класс белән театр куйган чаклар истә. «Беренче театр»ны уйнаган идек. Татар теле һәм әдәбияты укытучысы Бәнәнә апа Садыйкова (92 яшьлек укытучы бүген Лесхоз бистәсендә яши), ана телен яраттыру өчен, әсәрләрне шулай сәхнәләштерә иде. Лесхоздан Сабага ул вакытта туры юл юк. Бөркәүле йөк машинасына төялешәбез дә (үзебезчә аны «такси» дип йөртә идек) Иштуган авылына кадәр киләбез. Аннан Шәмәрдәнгә, анда ашханәдә җылынып алганнан соң, Сабага юл тотабыз. 60 чакрымга якын юл узарга туры килә иде. Иртәнге сәгать биштә торып, кышкы бураннарда укырга барулар рәхәт булмагандыр инде, шулай да ул чаклар күңелле мизгелләр булып саклана. Йөк машинасында бергәләп җырлап бара идек. Актив, дус булдык. Юллар салынгач, велосипедта да йөрдек. Рөстәм аеруча чаңгыда йөрергә яратты. Аның фотоаппараты бар иде. Төрле күренешләрне фотога төшергәнен хәтерлим. Интернатта торганда да бердәм булдык. Егетләр утын ярырга булышалар, кар көрилəр. Кызлар аш-су өлкәсендә ярдәм итәләр. Яшь буенча Рөстәм арабызда иң кечкенәсе булса да, барыбыздан да олы булды. Аның өчен бик сөенәбез. Классыбыздан Президент чыгу – безнең өчен зур шатлык. Мәктәпне тәмамлаганга 15 ел булдымы икән, Лесхозда халык «Карпат тавы» дип йөрткән бер бик матур елгалы урында сыйныфташлар белән очраштык. Ул чакта Рөстәм премьер-министр иде. Бик гади сөйләште, рәхәтләнеп, мәктәп елларын искә алдык. Сабан туйларында көрәшкәч тә, ачык сөйләшә.

1нче сыйныф. Укытучылары Римма Закирҗанова белән.

ҮЗ КЕШЕ

Миңнехановка – 60 яшь

Улының билгеләрен карый да: «Бу дөресме соң, арттырып куймыйсызмы?» – дип кызыксына. Беркайчан да, җитәкче баласы дип, Рөстәмгә ташлама ясаганыбыз булмады. Ул да башка сыйныфташлары кебек киенде, укыды. Мәктәптән тыш бәрәңге казырга, агач утыртырга йөрдек. Бергәләшеп туган көннәр уздыру гадәте бар иде безнең сыйныфта. Бер айда туган балаларны котлап, алар яраткан ризык әзерлибез, аш пешерәбез. Рөстәм пилмән ярата иде. Ул үз балам кебек кадерле, якын миңа. Күптән күрешкәнебез булмаса да, аны гел телевизордан карап торам. Ерак юлларга китә икән, Аллаһы Тәгаләдән исән-сау әйләнеп кайтуын телим, догамнан калдырмыйм.

ГОРУРЛЫК

Лесхоз сигезьеллык мәктәбен тәмамлаганнан соң, Рөстәм Миңнехановлар классы барысы да диярлек Саба мәктәбендә укуын дәвам итә. Булачак Президентны биредә укыткан мөгаллимнәр белән дә күрешергә насыйп булды.

Рәфидә Миңнеханова һич кенә дә Президентның туганы түгел, шулай да якын кешесе – химия, биология укытучысы.

– 9-10нчы сыйныфларда укыттым мин аларны. Рөстәм бик тыйнак, тырыш укучы булды. Укытучының аңлатканын бик игътибар белән тыңлый, кул күтәрмәсә дә, үзеннән сораганда, җавабы бик төгәл була иде. Тәртипле һәм җитди егет булып истә калган. Лаборатор эш вакытларында да үз янына чакырып, аңламаганын сорап, барысын да җиренә җиткереп эшли иде, – дип искә ала Рәфидә ханым.

Ул Президентның Инстаграм битен дә гел күзәтеп бара. «Укучым, көн саен хәерле иртә теләп, сәлам җибәрә», – ди, кесә телефонына ымлап.

ТАССРның атказанган укытучысы, Саба районы башлыгы урынбасары булып эшләгән **Нурислам Насыйбуллин** Президент укыган елларда мәктәптә директор булган. Бик төгәл, үзенчәлекле кеше икән Нурислам ага. 77 яшендә булса да, бөтен җиргә өлгерә. Һәр көн иртән салкын су белән коена. «Спорт көч бирә, Президентның да гел шулай активлыгы спортка битараф булмавыннан киләдер, кечкенәдән чыныгып үсте алар», – дип хатирәләре белән уртаклашты Нурислам ага.

– 1968-1984 елларда Саба мәктәбендә директор булып эшләргә туры килде. Мәктәптә 23 авылдан 300гә якын бала килеп укыды. Алар ике интернатта яшәде. Лесхоз сигезьеллык мәктәбе укучылары башкалардан үзләренең оешканлыгы, бердәм булулары, тормышка үзгә карашлары белән аерылып тордылар. Әти-әниләренең урман хуҗалыгында эшләүләре дә тәэсир иткәндер. Миңнехановлар классын мин физика фәненнән дә укыттым. Барысы да тырыш укучылар булды. Рөстәм Миңнеханов башкалардан аерылып тормады. Дәресләскә әзерләнеп килә иде, әмма кул күтәреп сөйләргә омтылмады. Барлык фәннәрдән дә «дүртле», «бишле» билгеләренә укыды. Алар интернатта яшәде. Шимбә көнне укучыларны йөк машинасы килеп ала, дүшәмбе иртәнге сигезгә мәктәпкә китереп тә куя иде. Рөстәм физкультура дәресләрен аеруча яратты, чаңгыда яхшы йөрде, ярышларда беренчелекне бирмәде. Кайвакыт Лесхозга кадәр 20 чакрым араны чаңгыда кайта иде. Иптәшләре белән яхшы мөгамәләдә булды. Кирәк чакта ярдәм итәргә әзер торды. Абыйсы Рифкать гел «бишле» билгеләренә генә укыды, энесенә аның да йогынтысы булгандыр. Кешенең шәхес буларак формалашуы гаиләдән килә. Балаларын Нургали Миңнеханович белән Васига апа тиешле контрольдә тоттылар, дөрес тәрбия бирделәр. Аларның сабырлыгы, уңганлыгы өч баласына да күчкән. Нургали ага гел, шалтыратып, улларының укуы белән кызыксынып торды, хуҗалык мәсьәләләрендә дә мәктәп аның ярдәмен тоеп яшәде. Саба мәктәбе коллективы Татарстанның икенче Президенты үзенең укучысы булуы белән һичшиксез горурлана, – ди Нурислам ага.

Кызганыч, Лесхозда да, Сабада да Президент укыган мәктәп бинаалары сакланып калмаган. Дөрес, район үзәгендә Рөстәм Миңнеханов укыган корпусны, ул яшәгән интернатны торак итеп үзгәрткәннәр, төзекләндергәннәр.

Президентның гаиләдә балалар санын арттыру турындагы фикеренә дә, беренчеләрдән булып, сабалылар колак салганнар булса кирәк. Районда туучылар саны сөбханалла диярлек. Алты балалар бакчасы исәпләнә, һәрберсенә 150шәр бала йөри. Әле бакчага чират та саклана ди. Ике зур мәктәп эшли. Ишле гаилә балаларын бушлай ашату да каралган. «Яшәү өчен барлык мөмкинлекләр дә тудырылган, шөкер. Саба халкы эшләп ашый», – ди Саба гимназиясе директоры Айгөл Хәнәфиева.

Кайсы укытучысыннан сорасаң да, Рөстәм Миңнехановның чаңгыда йөрергә яратуын һәм техниканы үз итүен аерым искә алалар. Мәктәпне тәмамлагач, әтисенең аңа иске генә «ГАЗ 69» машинасын алып биргәнен дә хәтерли авылдашлары. Егет үз көче белән барысын да өйрәнеп, кирәкле запчастьларны табып, бу машинаны йөрерлек итеп ремонтлап чыга алды, дип сөйлиләр. Техникага хирыслыгы, тизлек яратуы бүген дә сизелә. Рөстәм Миңнеханов – атказанган спорт мастеры да, автомобиль спорты белән шөгыльләнә. Президент – якташлары өчен генә түгел, барлык республика халкы өчен дә үз кеше. Аның нилэр белән кызыксынуы, кая баруы, кемнәр белән аралашуы берәүгә дә сер түгел. Инстаграм битендә дә ул тормышын, эшчәнлеген ачыктан-ачык чагылдырган фотоларын урнаштырып бара. Әле чит илдә татарлар белән очраша, республика өчен мөһим мәсьәләләрне хәл итә, ул да түгел, ветераннар белән хоккей уйный, улы белән балыкка барырга да вакыт таба. Президент сайлаулары вакытында халыкның 90 процентган артыгы аның өчен тавыш бирүе дә күп нәрсә турында сөйли. Бу ышаныч – бәһасез.

«Аз сөйләшеп, күп эшли»

Рөстәм Миңнеханов үзенең хезмәт юлын Сабада башлый. Башта «Сельхозтехника» берләшмәсендә инженер-диагност булып эшли. Аннары Саба урман хуҗалыгында өлкән энергетик, баш энергетик вазифаларын башкара, Саба районы идарә рәисе урынбасары булып тора. Сабада эшләгән чагындагы хезмәттәше, хәзерге вакытта лаеклы ялда булган ***Зәбәрҗәт Мөхтәсимова*** *белән дә аралаштык.*

– Рөстәм Нургалиевич белән беренче танышуым 1976 елда «Октябрь» колхозында булды. Ул чакта мин хисапчы булып эшли идем. Аны Казан авыл хуҗалыгы институтыннан, юллама белән, колхозга практика узарга җибәргәннәр. Әтисе Нургали Миңнеханов җитәкләгән Саба урман хуҗалыгы безнең колхозны шефлыкка алган иде. Урып-җыю чорларында, бәрәңге алганда бик булыша иде безгә. Аның улын бик якын кабул иттек. Ул тиз арада үз кешегә әйләнде, гәрчә җитәкче улы буларак аңа бернинди ташламалар да ясалмады. Рөстәм Миңнеханов беренче көннән үк эшкә кереште, авыр, пычрак дип тормады. 30 елдан артык бер тракторда эшләгән хезмәткәребез Юныс абый Идрисовның (хәзер мәрхүм), егетнең тырышлыгын, техникага хирыслыгын күреп: «Техника җене кагылган бу егеткә, ләкин укып бетергәч, безгә тәтемәс шул», – дигән сүзләре истә калган. Рөстәм Миңнеханов җыелышларда гел катнаша иде, студентлар, гадәттә, хәйләкәр була бит, практика нәтиҗәләрен үзләре язмый. Ә Рөстәм аңламаганын сорап, барысын да анализлап, төпченеп, өйрәнеп, хисап эшен үзе язганын хәтерлим. «Аны яклыйсы да бар бит әле», – дип әйтә иде ул.

Соңрак Рөстәм Миңнеханов белән бергә эшләргә дә насыйп булды безгә. 1981 елда Саба урман хуҗалыгында план-икътисад бүлегендә җитәкче булып эшли башладым. Ул вакытта анда Рөстәм Миңнеханов баш энергетик иде. Үз эшен җиренә җиткереп үтәүче, гади, тынгысыз булып исемдә калган. Ул чакта техника иске, кытлык заманы. Шундый авыр вакытларда да техниканы запчастьлар белән тәэмин итте Рөстәм Нургалиевич. Эзләнүчәнлеге, тырышлыгы әзсез узмады. Техниканың ремонтта тору вакыты кимеде, иске техника белән дә елына 100-120 мең кубометр агач чыгара алдык. Читтән килгән бер кеше дә аны директор улы дип башына да китерми иде. Киресенчә, әтисе аннан күбрәк тә таләп итә торган булгандыр әле. Һәрчак аз сөйләшеп, күп эшли торган кеше булды Рөстәм Миңнеханов.

ЙӨРӘК СЕРЕ

«Татнефть»нең Әлмәт медицина-санитария бүлегендә уникаль операцияләр ясала

Әнием, мәрхүмә: «Пычак астына кереп ятарга язмасын», – дип, гомере буе теләде. Авырудан ничек генә газапланмасын, операциядән курыкмаган кеше юктыр.

Зөлфия ХӘЛИУЛЛИНА

Зәйдә яшәүче Җәмилә Әгъзәмованың: «Мин операциядән бөтенләй курыкмадым», – дигән сүзләре башта ышандырмады. Әле бит операциянең нинди диген – йөрәккә!

– Операция ясарга кирәк булачак, дигән сүзне мин бернечә ел буена төрле табиблардан ишеттем. Әлбәттә, бәлки әле бөтенләй ясыйсы булмас, хәзер үк тә түгел ләбаса дип, үз-үземне ышандырып, ничекләр алдап килдем. Йөрәк исә үзен көннән-көн ныграк сиздерә башлады. Бакча башында яшәүче улларыма барып җиткәнче дә әллә ничә тапкыр туктыйм. Алай гына да түгел, ятып торганда да тын бетә, йөрәк туры кыза, кыса башлады. Шулай итеп мин Әлмәткә «Татнефть»нең медицина-санитария бүлегенә барып эләктем. Кардиохирургия бүлеге мөдире Сибагатуллин Нур Гасыймович белән булган беренче очрашуның әле дә булса һәр мизгелен хәтерлим, – дип, үзенең авыру тарихы битләрен ача Җәмилә Әгъзәмова.

Нур Сибагатуллин аның йөрәгенә иң элек җылы карашы, ягымлы сүзләре белән үтеп керә.

– Иң беренче аңа карап әйтәсе килгән сүзем «сез бик гүзәл кеше икән» дигән булса, икенчесе – Аллаһ сезне ничек минем юлыма чыгарды, ничек таптым мин сезне, дип уйладым. Нәкъ менә ул минем бөтен куркуларымны, шикләнүләремне таратты да куйды. Балалар курка, туганнарым: «Ничек курыкмыйсың?» – дип хәйран кала. Ышанасызмы-юкмы, мин операциядән бөтенләй курыкмый башладым. Йөрәкләренә операция ясалган башка кешеләрнең бик тиз аякка басулары да миндә ышаныч уятты, – ди яңа танышым.

Операция исә чыннан да гади генә булмый. Күкрәк читлеген ачмыйча гына клапанны алмаштырырга тиеш булалар. Бик тә гади итеп аңлатсак, бот төбеннән кан тамыры аша кереп, йөрәккә яңа клапан куела. Мондый операцияләр саны «Татнефть»нең медицина-санитария бүлегендә бүгенге көндә 40тан артык. Башлап җибәргәндә операциядә дөньякүләм танылган кардиохирург Ренат Акчурин үзе дә катнаша. Аны республикада бердәнбер булган гибрид операция бүлмәсендә ясыйлар.

– Табибларны тәнкыйтьләмәгән кеше сирәк инде ул, дәүләткә дә сүз җитәрлек әлегә. Минә калса, күбесе урынсыз, – ди Җәмилә Әгъзәмова. – Менә мине генә алыйк. Яңа тор операция ясыйсы булгач, күптәрле белгечләр бер ай тикшерделәр. Йөрәк кенә түгел, һәрбер органны аерым карадылар. Боларны түләп үтә башласаң, күпме акча кирәк булыр иде икән? Аннан соң миллион ярымлык клапан гына куйдылар. Болар өчен бер тиен акча түләмәдем. Һәрбер персоналның игътибарлылыгына, һөнәри осталыгына хәйран калырлык. Авыру кешене үзегез беләсез: әле берсе, әле икенчесе кәефсезләнә дә тора. Ник бер шәфкать туташы каты итеп эндәшсен, ямьсез итеп карасын! Һәркайсы шундый чибәр. Аптырагач, сезне монда конкурс белән җыйдылармы әллә, дип тә сорадым. «Без иң элек сүзебез, карашыбыз белән дәвалыйбыз», – диләр иде. Юк, алар кемнәндер куркып түгел, үзләре эшләгән хастаханәне яратып, бүлек мөдирләрен хөрмәт итеп башкаралар хезмәтләрен. Үзеңне мәҗбүриләп болай итеп эшләп булмый.

Җәмилә ханым мине озатырга чыкты. Без аның белән Зәй урамы буйлап барабыз. Үземчә, аның хәленә кереп, акрынрак атларга тырышам. Йөрәк хәтле йөрәккә операция ясалганга әле күп вакыт та үтмәгән. Ул исә, мине котмичә, алгарак ашыга. Күз тимәсен. Иртән юлга кузгалганда, Зәйдә Җәмилә Әгъзәмова белән очрашканнан соң, кире кайтырга иде исәп. Маршрутны үзгәрттек, бик тә мактаулы хастаханәне, табибны күрү теләге Әлмәткә алып китте.

ЯҢАДАН ТУУ

Йөзләгән операция ясаган, кешеләрнең йөрәген кулына тотып яшәү сулышы өргән табиб каршында утырам. Нур Сибагатуллин – медицина фәннәре докторы, профессор, хирург, Татарстанның атказанган табибы, 2015 елда «Ак чәчәкләр» премиясе лауреаты.

– Нур Гасыймович, үлем очракларының иң күбесе йөрәк-кан тамырлары авыруларына туры килә. Сәбәпләре нидә? Югыйсә бүгенге көндә бу өлкәдә медицина казанышлары да бик югары.

– Һәр авыруның тарихын кичә, бүген булган вакыйгалардан түгел, бернечә ел артка китеп эзләргә кирәк. Нәрсәдән башланган, нәрсә сәбәп булган. Кешенең сәламәтлеге өчен иң нык тәэсир итә торган әйберләрнең берсе, әлбәттә, стресс. Кешене нык сискәндерерлек вакыйгалар булган очракта, кан тамырлары кысылалар, димәк, кан йөреше дә үзгәрә, шул вакытта тромбоцитлар бүленеп чыга. Алар канны куертулар, тромблар хасил була. Тормыш көйсезлекләренә фәлсәфә белән карарга өйрәнергә кирәк. Һәр нәрсәне йөрәккә якын алмаска. Эштән көн саен арып, талчыгып кайту да бик какшата. Күңелгә якын бер шөгыль табып, ял итә белү дә мөһим. Физик күнегүләргә, дөрес тукланугә игътибарны арттырырга. Әлеге кагыйдәләрне яшәү рәвеше итеп алганда, йөрәк авырулары азрак булыр иде. Дөрес әйтәсез, үлем очраклары буенча йөрәк-кан тамырлары авырулары беренче урында тора. Бу әлеге өлкәдә медицина артта калган дигән сүз түгел, сәбәбе – йөрәкнең кеше яшәеше өчен иң мөһим орган булуында.

– Элек-электән кардиоүзәкләр бары тик зур шәһәрләрдә һәр өлкәдә бер генә диярлек булган. Ә монда Әлмәт шәһәрендә бу шушындый зур үзәк.

– Хәтта һәр өлкәдә дә юк әле ул. Россия буенча да алар санаулы гына. Әлмәттә, үзәктән читтә, заманча медицина үзәге салыну бары тик «Татнефть» җәмгыяте һәм аның җитәкчеләре хезмәте. Бина салу һәм аны иң алдынгы медицина җиһазлары белән баетырга, медперсоналны тупларга, белгечләрне чакырып китерергә кирәк бит. Без Уфадан бер команда – биш белгеч килдек. Һәркайсыбызга яшәү өчен тиешле шартлар тудырылган. Без моның өчен «Татнефть»кә бик рәхмәтле. Тагын шунысын да әйтергә кирәк, безнең «Татнефть» медицина-санитария бүлеге Ренат Акчурин белән хезмәттәшлек итә. Ул искитмәле кеше, аның һәр килүе безнең өчен зур бәйрәм. Әлеге үзәкне оештыру идеясе дә аның белән берлектә туган. Әйткәнемчә, йөрәк – кеше яшәеше өчен иң мөһим орган, бик тиз арада ярдәм күрсәтелмәсә, кешенең гомерен саклап калып та булмаска мөмкин. Безгә бер авыруны китерделәр. Аңа – 40 яшь, озын буйлы таза ир. Эшләп торган җиреннән кинәт кенә хәле авырайган. Аны инде үлеп беткән дип әйтергә була иде. Беренче карашка инфаркт булган кебек. Йөрәген тикшерәбез, бу расланмый. Бактың исә, үпкәсенә тромблар килеп кысылып, кан әйләнешен бөтенләй япкан икән. Тиз арада диагноз куеп, операция ясалды. Бу очракта нәтиҗәне минутлар хәл итә. Ерак барасы булса, тиешле җиһазлар яки белгечләр булмаса, аны саклап калып булмас иде. «Татнефть»нең кешеләр сәламәтлеге өчен күрсәткән игелекле гамәлләрен сумнар белән генә бәяләп бетерерлек түгел.

– Нур Гасыймович, Җәмилә ханымга ясалган операция дә бик гаҗәеп. Ничек инде күкрәк читлеген ачмыйча гына клапанны алмаштырып була? Башка сыймаслык эш кебек.

– Клапаннарны алмаштыру буенча операцияләр күп ясала. Бу очракта эш клапанның үзенчәлегендә дә. Ул биологик материалдан ясала һәм кысылып бик кечкенә формага килә, шуңа күрә аны кан тамыры аша да үткәрергә була. Тиешле урынга килеп җиткәч, ул зурая һәм үз формасын ала. Шушындый ук биологик клапаннарны күкрәк читлеген ачып та куябыз. Бүгенге көндә механик клапаннар кую буенча бик күп операцияләр ясала. Әлеге исул да начар түгел. Йөрәккә операция ясалганнан соң аны дөрес итеп тегү дә бик мөһим, чөнки йөрәктәге басым 120-200гә җитәргә мөмкин. Җөйләр шушы басымны күтәрә алырга тиеш. Монда инде җепләрнең, материалларның бик нык булуы кирәк.

Нур Сибагатуллин операция ясалган авыру кешеләрнең йөрәк клапаннарын күрсәтте. Кайберләрендә кан юлы капланып беткән диярлек. Йөрәгең ташмы әллә синең дигән сүз бар, баксаң, хәтта йөрәккә дә таш утыра икән. Һәрберсе – уникаль очрак, аның артында күпме борчулы төннәр, сызланулар ята. Кардиохирургия бүлегенә килеп кергән кеше үз йөрәген хирург кулларына тапшыра. Әлбәттә, Аллам сакласын, әнием әйтмешли, пычак асларына кереп ятарга язмасын. Шул ук вакытта әле ярый Нур Сибагатуллин кебек кешеләр бар. Аның белән әңгәмәдән соң мин үз йөрәгемне үтәли күрәм, аның хәлен аңлыйм кебек тоелды. Җәмилә ханым дөрес әйткән: ул синең йөрәгеңне иң элек үзенең ягымлы карашы, җылы әңгәмәсе белән дәвалый. Шуны да әйтергә кирәк, мондый белгечләр бу үзәктә күп, алар һәрберсе үз эшен намус белән башкара, яңалыкка омтылыш белән яши.

Наил МАГАНОВ, «Татнефть» компаниясенең генераль директоры:

– Нефть төбәгендә медицина ярдәме күрсәтүне югары дәрәҗәдә оештыру – «Татнефть» компаниясе социаль сәясәтенең иң зур өстенлеге. Гибрид операция бүлмәсе ачылу – Татарстанның көньяк-көнчыгышында сәламәтлек саклауның үсешенә зур бер адым.

Ренат АКЧУРИН, кардиохирург, академик, Россия кардиология фәнни-җитештерү үзәгенең Клиник кардиология институтының йөрәк-кан тамырлары авырулары бүлеге җитәкчесе:

– Татарстанда бу – беренче гибрид операция бүлмәсе. Заманча медицина технологияләренең үсеше, аларны көндәлек медицина практикасында куллану хирургларга бик күп пациентларга булышырга мөмкинлек бирә. Кызганыч, моңарчы без аларга ярдәм итә алмый идек. Мин «Татнефть» медицина-санитария бүлеге хезмәткәрләренә бик рәхмәтлемен. Бу – фикердәшләр коллективы, алар – теләсә кайсы проблеманы хәл итә ала торган белгечләр.

Мөнир ЗАКИРҖАНОВ, «Татнефть»нең Әлмәт медицина-санитария бүлегенең баш табибы:

– Гибрид операция бүлмәсе ачылу – безнең медицина үзәгендә соңгы елдагы казанышларның иң зурысы. Авыруларны еракка җибәрмичә, дөньяда булган алдынгы ысулларны кулланып, үзебездә дәвалый алабыз.

ЗӘЙ ҺӨНӘРЧЕЛӘРЕ

ОСТА КУЛЛАР

Зәй районында кызлар кияү йортына бирнәләрен сандыкка тутырып килә икән. Чишмәдән су ташырга үзләре белән көянтә дә алып баралар ди. Туку станогында тукылган карават җәймәләре, идән паласлары аларда беркайчан да модадан чыкмаган. Зәй ягында урманга чабата киеп баручыларны күрсәгез дә аптырамагыз. Биредә ата-бабалардан калган һөнәрләр әле булса югалмаган, аларны дәвам итүчеләр биредә шактый.

Илдар Мөхәммәтҗанов фотолары

Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА

САНДЫКНЫҢ УРЫНЫ – ТҮРДӘ

Шундыйларның берсе – Югары Шепкә авылыннан Рәйхат Сафиуллин. Сандыклар ясау остасы ул. Туган авылына биш-алты ел элек кайтып яши башлаган.

– Егерме елдан артык шофер булып эшләдем. Хәзер йортлар төзү, түбә ябу эшләре белән шөгыльләнәм. Әтиебез балта остасы иде, бала вакытта ук мине үзе белән бура бурарга йөртте. Агач эшенә хирыслык аннан дип уйлыйм. Соңгы вакытта татар халкының борынгыдан килгән һөнәр үрнәкләре кире кайта башлады. Минем дә сандык эшләп карыйсым килде. Кыш көннәрендә буш вакыт күп була, ә кул эшсез торырга күнекмәгән. Сандык ул урындык, өстәл ясау түгел. Аның үзенең бер хикмәте бар, ул бит безнеке – татарларныкы. Яшь киленнәр, ак әбиләр өчен иң кадерле әйбер булган, – ди ул.

Биш-алты елда ул 30лап сандык ясаган, берсен ясау өчен ике атналап вакыт кирәк. Рәйхат абыйның сандыкларын үз районнарыннан гына түгел, Мөслим, Бөгелмә, Сарман, Түбән Кама, Чаллыдан да килеп алалар. «Мине иң сөендергәне: кызлар кияү йортына бирнә сандыгы белән бара башладылар», – ди Рәйхат абый.

Көянтәләр ясау уе да бар аның.

– Әти орчык кыра, баш тарагы, көянтәләр ясый иде. Ул эшләп калдырган көянтәләрне әле дә сорап килаләр. Шул эшкә үзем дә тотынырга уйлыйм. Аларын да кияүгә барырга җыенган яшь кызлар сорый. Безнең авылда килен булып төшкән кызларга су юлын күрсәтәләр. Чишмәдән алып кайткан суын ул сата. Суын эчкән кеше чиләгенә тимер акчалар сала. Су юлын күрсәтүчегә махсус бүләк тә әзерләп куя. Авылда шундый йола саклана, – ди ул.

«ЧАБАТА АЧЛЫКТАН САКЛАДЫ»

Имәнлебаш авылыннан 81 яшьлек Минзәкия Гаптерәхимова хәзер дә чабаталар үрә.

– Ходай сакласын, тагын чабатага кучәргә язмасын. Авылыбызның «Җәүһәр» исемле ансамбле бар, чыгышлар ясаганда, аякка чабаталар кирәк булды. Бала вакытта аны көн дә үрә идек, искә төшерү авыр булмады. Әти сугышка китте, шуннан кайтмады. Әни дүрт бала белән ялгыз калды. Олы апабыз чабатаны үрә, ә мин базарга барып аларны сата идем. Аңа ул вакытта 15 яшьләр тирәсе иде, көненә бер пар чабата үрде. Базардан:

«Кызарып кояшлар чыккач,
Китәм иртүк базарга.
Чабаталарымны сатам
Җирки базарында», – дип такмаклап кайта идем. Кечкенәдән такмаклар җырларга яраттым.
«Чабатасы-катасы,
Ярым да юк,
Кайгым да юк,
Кайтасы да ятасы», – дип такмаклап йөргәнемне дә хәтерлим. Бервакыт олы апаны үртәп, тузма язмаган җырлар җырлап утыра идем, ул ачуланып, чабатасын урталай ярды да, менә хәзер шуны кияр-сең инде, дип, миңа ыргытты. Шуннан елый-елый, үзем чабата үрергә өйрәндем. Чабата ясарга юкә курысын табу ансат түгел иде. Урманчы күрсә, судка бирергә мөмкин. Берьюлы 200 юкә курысы кисеп чыктык. Юлда урманчы күрде. Безне судка бирмәсен дип, әни аңа күп итеп май, он, күкәй биреп җибәрде. Шул вакытта: «Котылдык», – дип сөенгәннәребез! Менә шундый еллар да бар иде. Чабата үрү ул чорда тамак туйдыру өчен төп һөнәр булды, – дип искә ала ул бала вакытларын.

Чабата өчен юкә курысын җәй көне үк әзерләп куя ул, аны соңга калмыйча – юкә бал бирә торган вакытта ук алып кайтып куярга кирәк. Курыны тәреп куеп, базда саклый, ул анда ныгый, ди. Чабатаны җәй көне урманга җиләккә киеп барыргa дип сораучылар да табылган.

– Әллә кызык ясап, әллә чынлап та җайлы күрәләрме – аңламассың, – дип көлә Минзәкия апа.

Мәктәп балалары арасында да чабата үрергә өйрәнергә теләүчеләр бар икән. Кызы да, кияве дә өйрәнергә ниятләп торалар. Чабата ясаганда кулланыла торган шөшләсе – әтисеннән калган бердәнбер истәлек. «Шөшләне дә, чабата үрү серләрен дә аларга биреп калдырасым килә», – ди Минзәкия апа.

ФРАНЦУЗЛАРНЫ ДА ШАККАТЫРГАННАР

Зәй районының Куш-Елга авылы традициягә кереп киткән «Ашыт җыены» фольклор бәйрәме белән генә түгел, туку станокларында идән паласлары сугучы әбиләре белән дә данлыклы. Үткән гасырның агач туку станогында алар безгә идән паласы тукып күрсәтте. Әбиләрнең суккан җәймәләрен тел шартлатып карап йөрүебезне күреп, үзләре дә гаҗәпләнде.

– Сезнең мондый паласларны күргәнегез юк идеме әллә? – дип елмаештылар алар.

Туку станогының ничек итеп эшләве турында кат-кат сораулар бирә башлагач, бер әби янәшәсендә утырганына: «Әллә боларның әниләренең бер дә җәймәләр суккаы булмаганмы?» – дип пышылдап әйтүен ишетеп, без дә рәхәтләнеп көлдек. Музейларда гына күреп ияләшкән мондый паласлар, карават япмалары, кашага, тәрәзә пәрдәләре һәр йортта бар икән бу авылда. Куш-Елга һөнәрчеләренең эшләнмәләре Казанга да, Самарага да, Мәскәүгә дә, Ташкентка да киткән. Тукучы әбиләр белән хәтта Франциядән килгән кунаклар да танышкан. Алар да идән паласларын күреп шаккаткан.

– Районда уза торган чараларга, күргәзмәләргә алып баргач, халык: «Сатыгыз әле», – дип аптыратып бетерә. Бер тапкыр җәяргә генә ярый торган, юсаң, ишелеп төшә торган паласлар түгел шул инде болар. Күпмә юсаң да, төсләре уңмый, алып кагарга да җиңел, юарга да ансат. Хәзер халык әйбәт әйберне аера башлады, – ди Икълимә апа Юнысова.

Нәкыя Гарәфетдинова әйтүенчә, элек тукырга әйбер булмагангда, иске чүпрәкләрне кисеп суга торган булганнар. Әнисенең андый паласлары әле дә саклана икән. Аларны төрле төстәге буяуларга манганнар. Буяуларны Ташкенттан, Ижевскидан кайтартканнар яки вак товар сатучыдан алганнар.

Гасимә апа Муфаздалова кайчандыр ире ясап биргән туку станогын авыл клубына алып менеп куйган. Хәзер ул станокта мәктәп балалары да палас сугарга өйрәнә.

КУЛЛАРЫННАН ГӨЛЛӘР ТАМА

Югары Шепкә авылында яшәүче Рәфинә Мостафина да кул эшләренә оста. Ул ясаган һәр эшләнмәдә аның кул җылысы, күз нуры, күңел матурлыгы саклана. Никахларга чәк-чәк, бавырсак пешерергә кирәк булса, аңа мөрәҗәгать итәләр. Сабан туе җитсә, бүләк җыяр алдыннан яшь киленнәр аңардан сөлге чиктерә. Яшь киленнәрдән бүләккә фәкать сөлге алу – авылда борынгыдан сакланган бер матур йола. Туйларга атлас ленталардан кәләш букеты да әзерләп бирә. Мендәр тышларын да бик матур итеп чигә Рәфинә ханым. Мәдәният йорты директоры булып эшләгәч, үзләренең ансамбльләре костюмнарын бизәү дә аның өстендә. Күлмәкләр өстеннән кия торган түшлекләрне сәйләннәр белән чиккән. «Түбәтәй чигәргә дә өйрәнәсе килә әле», – ди ул.

Үзенең әйтүенчә, кул эшләренә осталыгы әтисеннән килә.

– Хәтерлим әле, кечкенә генә өебезгә кыш көне яңа туган бозауны да, сарык бәрәннәрен дә кертә идек, без бала-чага да шунда кайнашабыз. Әтиебезнең, тезләнеп, тәрәзә йөзлекләре өчен бизәкләр кисүе, икешәр урындыкны янәшә куеп, шуңа йөзлекләрне яткырып, бизәкләр төшергәне хәзер дә күз алдымда, – ди ул.

Рәфинә ханымның кул эшләнмәләреннән тулы бер күргәзмә эшләп була. Безне аның кул эшләренең төрлелеге, матурлыгы, зәвык белән эшләнелеше сокландырды.

Язманы әзерләүдә булышкан өчен, Зәй районы мәдәният бүлегенә рәхмәтебезне җиткерәбез.

АРБАНЫ КЫШТАН ӘЗЕРЛӘ

АРЗАНЛЫ ЯЛ

Җәй таулар артында түгел, күз ачып йомганчы килә дә җитә. Ә җәй – яллар чоры. Берәр кая ял итәргә барып кайту турында уйлаучылар аның хәстәрен бүген үк күрә башласа да була.

Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА

ИҢ АРЗАНЫ – ТӨРКИЯ

«Спутник» виза үзәгенең коммерция директоры Артем Латыйпов әйтүенчә, ялны алдан ук планлаштырып кую мәслихәт. Март ахырына кадәр җәйге турлар кышкы бәяләрдән сатыла. Алар якынча 20, хәтта 30 процентка арзанрак була.

– Туристлык агентлыклары кышкы сезонда ташламалы турларга махсус акцияләр дә уткәрә. Иренмичә, турфирмаларга шалтыратып, акция булу-булмавы турында кызыксыныгыз, – ди ул.

Кайберәүләр ялга бернинди юлламасыз гына чыгып китә. Ул үзен һәрчакта да аклыймы? Әлеге сорауны мин әңгәмәдәшемә бирми кала алмадым.

– Греция, Италия, Испания кебек илләргә юллама белән бару арзанграк та чыга. Ә инде үзебезнең Сочи, Кырымнарга машина, поезд белән бару отышлырак. Шунысын да истә тотыгыз, чит илгә барганда, туры рейслар кыйммәткәрәк чыга. Берәр илдә күчеп утыра торган маршрутларны сайлагыз. Кесә ягы такырак булса, визасыз илләргә барырга киңәш итәм.

– Кайсы илләргә бару чагыштырмача арзанрак?

– Төркия һәм Болгария. Соңгы вакытта Греция дә арзанайды. Турларга берничә ай алдан заказ биреп кую да акчагызны янга калдырырга булыша. Җәйге сезонга алар җиде-сигез ай кала ук чыга. Испания, Греция, Болгария, Хорватия пляжлары быел да тулачак. Әлеге илләргә барырга теләүчеләр җәйне көтеп утырмаса да була. Җәйгә таба алар кыйммәтләнергә мөмкин. Кыскасы, алдан аягын киюче барыбер ота.

Артем Латыйпов сүзләренчә, яллар чорына юлламаларның бәясе 15-30 процентка артачак.

ОФИЦИАНТЛЫ КАФЕЛАРГА КЕРМӘГЕЗ

Элеккеге хезмәттәшебез Эльмира Кәримова сәяхәткә ялгызы гына йөрергә ярата. Әллә ничә илдә булып, аның бер тапкыр да туристлык фирмасыннан юллама алганы юк. Барасы илен алдан ук интернеттан өйрәнеп, маршрутын төзеп, билетларын алып куя да бисмилласын әйтеп тәвәккәлләп чыгып китә. Сәяхәтче булачак тәҗрибәсе күп. Аңардан да ялны ничек арзанрак итеп оештыру серләрен сораштым.

Эльмира Кәримова мөстәкыйль сәяхәт иту яклы.

– Юллама алып бишәр йолдызлы отельләрнең комфортлы бүлмәләрендә яшәү, диңгез ярында яту, бәлки, отышлырактыр да. Ә экскурсияләрне яратучыларга, миңа калса, мөстәкыйль чыгып китү яхшырак. Google картадан хәзер бөтен кеше дә куллана белә, үзеңә кирәк урынны, аның турындагы мәгълүматны аннан тиз табасың. Гомумән, интернет – сәяхәтче өчен менә дигән иптәш инде ул, – ди илләр гизүче Эльмира.

Аның сүзләренчә, акчаны янга калдыру иң беренче итеп визаны үзең алудан башлана. Агентлыклар бу очракта курьер вазифасын гына башкара. Ә әлеге хезмәт өчен синнән акча да ала. Самолетка билет алуга килгәндә, бәйрәмнәрдә, каникул көннәрендә билетлар кыйммәтрәк була икән. Шулай ук билетларны ял көннәрендә алмау да хәерле.

– Билет бәяләре самолетның ни дәрәҗәдә тулы булуына да бәйле. Анда буш урыннар күп булганда, бәясе арзанрак. Тулып бетә язганда, кыйммәтләнә. Самолетны ничәдер процентка тутырып бетергәч, аларга берничә урынның буш калуы куркыныч түгел, шуңа да бәяне күтәреп куялар. Теге яки бу җиргә барганда, туры рейска караганда, берәр илдә күчеп утыру арзанракка чыга. Шуның өстенә ул сезгә берьюлы ике илне күрү мөмкинлеген дә бирә. Берничә көнгә ул илдә калып, аннары сәяхәтегезне дәвам итә аласыз. Әмма моны алдан – билет алганда ук планлаштырыгыз. Минем үземә Балкан илләре: Босния, Герцеговина, Албания, Черногория, Македония ошый. Анда әлегә Россия халкы бик күп йөрми. Анда виза да кирәкми, табигатьләре дә матур, карарлык урыннары да күп, диңгезгә дә чыгып була. Анда бару өчен мин башта Төркия аша Сербиягә очам, Мәскәү аша да очарга була. Сербиядән инде юлыңны автобуста дәвам итәсең. Самолет төшеп утырасы шәһәр зур булган саен, анда билет бәясе дә арзанрак. Кечкенә шәһәрләргә исә кыйммәтрәк чыга. Тагын бер киңәшем: кайбер лоукост-авиакомпанияләрдә самолет билеты чагыштырмача арзан санала, әмма аның тискәре яклары да бар. Билеты арзан, әгәр дә ашау аласың икән, үзең белән багажың булса, алар өчен акчаны өстәмә түлисең. Болар белән билет бәясе артып та куярга мөмкин. Билетларның кире кайтарып булмый торганнары шулай ук арзанракка чыга. Барасыңа тулы ышаныч булганда, нишләп әле шул билетны алмаска?! Шунысын да әйтергә кирәк: Испания визаны алты айга бирә, Италия – өч айга. Ә кайбер илләр син барасы көннәргә генә. Испаниядән кайткач, ярты ел эчендә Евросоюзга кергән тагын берәр илгә чыгып керә аласың, чөнки визаң ачык була, – дип киңәшләрен бирә әңгәмәдәшем. – Кунакханәләргә тукталганчы, хостел яки гестхауслар арендалау күпкә очсызга төшә. Әгәр дә сез анда йокларга гына кайтасыз икән, фитнес, бассейн, ресепшннар өчен акча түләү нәрсәгә? Гестхаус дигән яңа сүз – берәр йорт хуҗасының бер бүлмәсен арендага бирүе. Ул бүлмәләр туристлар өчен махсус җайлап эшләнелгән, бәдрәфе дә, ванна бүлмәсе дә бар.

Сәяхәткә чыгып китәр алдыннан booking.com сайтына кереп карагыз. Анда үзеңә кирәкле датага, үз кесәңә туры килгән бәядән кунакханәләр, йортлар, бүлмәләрне шактый табарга була. Алар турында шактый мәгълүмат та бирелә, үзәктән ничә чакрым ераклыкта урнашкан, янәшәдә нинди кафелар бар – барысы да күрсәтелгән. Бик җайлы сайт ул. Гестхаус бер кеше булганда яхшы, ә дүрт-биш кеше барган очракта инде фатир арендалау отышлырак. Туклану мәсьәләсенә килгәндә, официантлы кафеларга керергә кирәкми, чөнки сез аларның хезмәте өчен дә түлисез булып чыга. Пекарнялар, фастфуд булган җирдә туклану арзан, әлбәттә. Кайбер илләрдә, әйтик, Италиядә кафега кереп каһвә алганда, синнән, монда утырып эчәсезме, дип сорыйлар. Әйе дисәң, каһвәнең бәясен ике тапкырга күтәреп куялар. Үзең белән алып чыгып, берәр эскәмиягә утырып та эчеп була бит. Гестхауста ашарга пешерергә плитә дә була, продуктларны базардан алып кереп әзерли аласың, – дип сөйли Эльмира.

Шәһәр белән танышу барышында да акчаны янга калдыру җае бар икән, әйтик, музейларга кергәндә. Барлык эре музейларда аена бер тапкыр керү бушлай куелган. «Ял итәргә барыр алдыннан шул мәгълүмат белән танышыгыз», – дип киңәшләрен бирде илләр гизүче Эльмира.

БЕЛЕП ТОР!

! **Туристлык сезоны булмаганда, ял очсызгаракка төшә. Яңа ел бәйрәмнәре, май бәйрәмнәреннән соң, шулай ук сентябрьдә юлламаларның бәясе күпкә арзан була.**

! **Шопинг яратучылар ялларын кибетләрдәге ташламалар сезоны вакытында ала. Россиягә караганда, Америка һәм Европада ташламалар күбрәк була.**

! **Ял итәргә парлап йөрегез. Кунакханәдә ике кешелек номерлар, бер кешелеккә караганда, арзанрак тора.**

! **Егетләр бушка автостоп белән хәрәкәт итә ала.**

! **Күңел ачу парклары, шарлавык, күзәтү мәйданчыклары, музейларга керү билеты атна уртасында арзанрак.**

! **10-50 музейны карау һәм җәмәгать транспортында йөрү хокукын бирә торган туристлар карточкасын сатып алганда кат-кат уйлагыз. Күпләр ике-дүрт музейны гына карарга өлгерә. Бәяләрне һәм бер-берсеннән нинди ераклыкта урнашуын өйрәнегез, бәлки, аерым алу арзанрак булыр.**

! **Кафе-рестораннарда ланч вакытында тукланыгыз. Бизнес-ланчлар – берничә ризык җыелмасы – менюдагыга караганда, күпкә арзанракка чыга.**

! **Сувенирларны соңгы көнне генә алыгыз. Шәһәр белән танышканда, аларны күпкә очсызгаракка табачаксыз. Сувенирлар туристлар күп була торган урыннарда, аэропортларда кыйммәткә сатыла.**

КҮК КУНАКЛАРЫ

Ул көнне студент улым иртән үк метеорит турында сөйли башлады. Ә мин, әллә кайчан, 1908 елда ук тайгага төшкән Тунгус метеориты турында яңа кызыклы мәгълүмат тапкан бугай бу, дип уйладым. «Юк, бүген төшкән, Уралга», – дип, улым планшетыннан шушы яңалыкны күрсәтеп, һәммәбезне шаккатырды.

БУЛМАС ДИМӘ

Карлы метеориты кыйпылчыгы.

Миллион ел элек Карлы метеориты кратерының мөмкин булган күренеше.

Йолдыз ШӘРАПОВА

Шул көннән башлап, барлык мәгълүмат чаралары ул метеоритны җиде килештә тәрләндерде. Бернечә ел элек гаиләбез белән Уралга сәяхәткә барып, бу кырыс, ләкин шул ук вакытта искиткеч гүзәл табигатьле якларны яратып кайткан идек. Нәкъ менә Чиләбе, Миасс тирәләрендә булырга, андагы халык белән очрашырга туры килде. Әлеге хәбәрне ишеткәч тә, мәгърур Урал, утә күренмәле тау кулләре кабат күз алдыма килде.

Нәкъ дүрт елдан соң, әлеге вакыйгаларга кабаттан әйләнеп кайтып, күктән нинди кунак төшүен «Википедия»гә нигезләнеп, аңларга, күз алдына китерергә тырышып карыйк.

«2013 елның 15 февралендә жомга көнне якынча 9 сәгать 20 минутта Чиләбе шәһәре өстендә 15-25 км биеклектә метеорит шартлаган. НАСА галимнәре фикеренчә, аның диаметры – 17 метр, авырлыгы 10 мең тонна булган. Атмосферада ул ваклангән, аңардан чыккан энергия тротил эквивалентында якынча 440 тонна тәшкил иткән». Билгеле инде, мондый галәм кунагы Җиргә шактый бәла-казалар китергән. Күп кенә торак йортлар, балалар бакчалары, мәктәпләрнең тәрәзә пыялалары коелып төшкән. Спорт корылмалары, заводлар зыян күргән. Пыяла ватыклары белән яраланучылар, башка җәрәхәтләр алучылар саны да меңнән артык булган. Җитмәсә, алдагы төнне генә астрономнар бер астероидның Җиргә бик якын (27,7 мең километр) килүе турында хәбәр иткән булганнар. Теге майлар әйткән, бөтен Русия халкы дер калтырап көткән «дөнья бетәсе көн» – 2012 елның 21 декабреннән соң да әллә ни күп вакыт узмаган. Шуңа күрә халык чын-чынлап куркуга төшкән, нәрсә уйларга да белмәгән.

Без бу хәлләрдән ерак торсак та, күңелебез белән алар янында булдык. Ул яктан ирешкән һәрбер яңалык туганыңнан килгән кебек кабул ителде ул көннәрдә. Чиләбедән Казанга кунакка килгән шәһәрнең 81нче мәктәбе укытучысы Сания ханым Вахитова, шактый вакыт узса да, ул көнне тыныч кына хәтерли алмый.

– Мин ул чакта дәрестә идем, 2нчеләрдә, – дип сөйли ул. – Кинәт бөтен дөнья бик нык яктырып китте һәм каты шартлау ишетелде. Балалар, куркышып, парта астына качты. Ни уйларга да белмәдек, башта берәр самолет һәлакәткә очрагандыр, дип белдек. Безнең шәһәр өстеннән хәрби самолетлар еш оча бит. Атом гөмбәсе юкмы, дип, тәрәзәгә карасам, анда ике ак юл күрдем. Ул да булмады, мизгел эчендә классның барлык тәрәзәләре дә коелып төште, нәниләрем елый башлады. Аларны ни дип юатырга да белмим, үземне берәрсе юатсын иде әле. Нәрсә булганы үземә дә мәгълүм түгел. Шулай да гадәти булмаган ниндидер бер куркыныч хәлне сиземләве кыен булмады. Йөгереп коридорга, аннары ишегалдына чыктык, балаларны әти-әниләре килеп ала башлады. Миннән, еш кына: «Курыктыгызмы?» – дип сорыйлар. Эчендә җаны булган кеше ничек курыкмасын инде, куркыттык, билгеле. Җитмәсә, кесә телефоннары эшләми башлады, хәбәр дә итешеп булмый. Мондый хәлне беркайчан да күргән юк иде бит. Кеше никадәр генә «Мин!» дип күкрәк кагып йөрсә дә, бар яшәеш күз ачып йомган арада юкка чыга ала, Җирдән дә тузан бөртеге генә калырга мөмкин икәнен аңладык. Шуңадыр шәһәр халкы күзгә күренеп үзгәрде. Бер таныш булмаган кешеләр бер-берсенең хәлен сорашып, ярдәм кулы сузды. Ничектер без бөтенебез авырлык килгән бер гаилә әгъзалары на әйләнеп калгандай булдык. Аяк астыннан чыккан (дөресрәге, күктән төшкән) көтелмәгән бәла безнең барыбызны да яшәү мәгънәсе турында уйланырга мәҗбүр итте. Шуңадырмы, меңләгән йортларның ишек-тәрәзәләре ачык булуга карамастан, шәһәрдә урлау-талау очраклары ишетелмәде. Җан саклау беренче урында булганда, мал кайгысы онытыла, күрәсең. Шөкер, балаларым да, үзем дә зыян күрмәдек, Ходай саклады. Ләкин кыш уртасында тәрәзәсез калуны дошманыңа да язмасын. Әйткәнемчә, бөтен халык бер булып, бик тиз генә, бу бәлагә каршы көрәшкә күтәрелде. Дүшәмбедән укый башладык инде...

Батырлык үрнәге күрсәткән гади кешеләр турында да ишеттек. Мин үзем, шәхсән, укучыларын коткарып, үзе каты җәрәхәтләр алган укытучы Юлия Карбышева батырлыгына сокландым. Хәер, мондый билгеле һәм билгесез батырлар ул көннәрдә күп булгандыр инде.

Вакыйга никадәр тәэсирлерәк булса, аның имеш-мимешләре дә шулкадәр күбрәк була. Монда да нәкъ шулай булды, мәгълүмат чаралары бер-берсен уздырырга тырышып, сенсация эзләде. Имеш, ул метеорит та булмаган, берәр яңа коралны сынап караганнар. Имеш, аны Җиргә бәрелүдән «очар тәлинкә» саклап калган...

Озак эзләгәннән соң, бу метеорит кыйпылчыкларын Уралның Еманжелинск шәһәреннән ерак булмаган Чибәр күлдән таптылар. КФУның космик геодезия кафедрасы мөдире, профессор, Татарстанның Фәннәр академиясе академигы Наил Сәхибуллин бер әңгәмәсендә Җиребезнең һәрчак зур куркыныч астында торуын, баш өстебездә меңләгән кече планеталар, астероидлар, кометалар әйләнүен әйткән иде. «Мин илләрнең бер-берсенә сугыш башлауларын, халыкларның дошманлашып яшәүләрен һич аңлый алмыйм. Безгә бит барыбыз бер булып, уртак йортыбыз Җир шарын, кешелекне коткарып калу турында уйларга кирәк!» – дигән иде ул.

Әйе шул, чынлап та, көнчелек, хөсетлек тулы күңелләребезне күтәреп, дөнья байлыгы артыннан чабып әлсерәгән бер мәлдә безгә тукталып: «Дөрес яшибезме? Күкләр безнең гамәлләргә ни дияр?» – дип уйланырга кирәктер. Шөкер, бу юлы исән калдык, күкләр безгә тагын бер шанс бирде. Ләкин андый бәхетле очраклар киләчәктә дә булырмы-юкмы? Бу сорауга җавапны бары тик бар галәмнәрнең хуҗасы булган Бөек Иҗатчы гына белә. Ләкин ул шанс безнең эш-гамәлләребез белән турыдан-туры бәйләнгән булырга да бик мөмкин бит. Күнелдә «биш яшеннән йолдызлар илендә адашкан», ә бүген Галәмдә үз кече планетасы әйләнүче классик шагыйребез Хәсән Туфанның «Йолдызлар» шигырендәге юллары яңара:

Әнә бит ымлаша төньяктан,
Төшенмиммени соң мин аны:
Офыклар буталып бетсә дә,
Кыйбланы бутама, кыйбланы!

Дүрт ел элек, беркем көтмәгәндә-уйламаганда утлы шар булып Җир өстенә атылган Галәм илчесе – күк кунагы да безне шул хакта тагын бер кат искәртергә теләмәдеме икән?!

Язмамны язып бетерергә торганда, элеккеге хезмәттәшем шалтыратты: «Син Карлы метеориты турында берәр нәрсә беләсеңме?» – дип сорады. Оялып кына: «Юк», – дидем. Туган ягың турында аз белүеңне күрсәтү рәхәт түгел бит инде ул. Безнең якның тагын бернечә кешесеннән сорап карадым: алар да ишетмәгән-белмәгән булып чыкты. Аннары теләсә нинди сорауга җавап табып була торган интернетка кереп карадым. Анда шактый мәгълүмат таптым. Бу метеорит моннан 5 миллион еллар элек Буа районына төшкән икән. Исеме Карлы елгасы атамасыннан. Диаметры – 10 чакрым. Районның хәзерге Протопопово, Ямбулат авыллары тирәләрендә. Гомумән, галимнәргә Татарстанга төшкән биш метеорит билгеле. Алар башлыча үзләре килеп төшкән җир атамасы белән исемләнәләр. 1937 елда Мөслим районы Каенсаз авылы басуына бер утлы шар төшә. Аны басуда урак уручы хатын-кызлар күреп кала. Тагын 1899 елда Аксубай районының Кисы авылы янына да күк кунагы төшүе билгеле. Өченчесе – Лениногорск районы Ивановка авылы янында. Ә Кайбыч районы Арыслан авылы янындагысы 2011 елда гына кызыксынучан малайлар ярдәме белән табылган. Ләкин галимнәр аның 100 ел элек төшкән булуын фаразлыйлар.

Метеорит дип әйтүгә иң беренче Тунгус тайгасына төшкәне, аннары Чиләбенеке искә төшә. Баксаң-күрсәң, үзебездә дә бар икән мондый күк кунаклары. Тукай сүзләре белән әйтсәк, «Күктә ниләр булмас диген, очсыз-кырыйсыз күк бит ул...»

Һәрбер әти минеке кебек булсын

Әтием Рафис Рафаэль улы Әхмәдиев 1972 елда көзнең иң мул аенда дөньядагы иң матур авылларның берсе – Саяда дөньяга килә.

Ул – әти-әнисенең беренче уллары, ышанычлары, өметләре. Әтием бик тыныч һәм бик акыллы бала була. Дәү әтисенең уң кулы астында үсә. Алга китеп шуны әйтәсем килә, ул дәү әнисеннән тәмле аш-су әзерләү серләрен өйрәнеп кала һәм әнием белән безгә 8 Март – хатын-кызлар бәйрәмендә ел саен кәнфит кайнатмасын әзерли.

Әтиемнең балачагы Кышлауда сыер караулап, Ак бияда дуслары белән су коенып, Чорлак ярларында пешкән җир җиләкләре ашап, Ясаклы урманына чикләвек, гөмбәгә йөреп үтә. Кышын бишмәт итәкләре бозга катып беткәнче, дуслары белән окоп ясап, кар бәрешеп уйный, авылыбызның иң биек Мөхетдин тавыннан чана-чаңгыда шуа, үзе агачтан ясаган кәшәкә белән хоккей уйный.

Мәктәпне уңышлы гына тәмамлап, һөнәри училищега кереп, әтисе юлыннан китәргә була. Укып бетерүгә, илне сакларга армия сафларына китә.

Кытай чигендә алты ай сержантлар мәктәбендә укый. Ул анда төрле техника һәм сугыш коралларын кулланырга өйрәнеп, Әфган чигенә җибәрелә. Чик сакчысы булгач, төрле хәлләргә очрый. Чик бозучыларны кулга алып, сигезенче заставага озаталар. Андый хәлләр күп була, чөнки әтием хезмәт иткәндә, Әфган сугышы беткән вакытлар.

Әтием чик сакчысы булуы белән бик горурлана. Алар ел саен үзләренең бәйрәмендә – 28 майда, иптәшләре белән очрашалар. Үзенең яшел фуражкасын, ак якалы камуфляжын киеп чыгып киткәндә, әтине гаиләбез белән озатып калабыз.

Армиядән кайтып озак та үтми, әтием үзенә тормыш юлын үтәр өчен үз авылы кызы – әниемне сайлый һәм дөньяга бер-бер артлы мин һәм энем аваз сала.

Минем әтием алтын куллы, нинди генә эшкә тотынса да, җиренә җиткереп башкара. Безнең өйдә аның кулы тимәгән бер генә әйбер дә юк. Чыгарып ташларга диган әйберне дә өр-яңа итеп эшләп бирә. Икмәк тарттыру корылмасын да үз куллары белән эшләде. Тимерне эретеп ябыштыру эшләрен дә үзе эшли. Авылыбызда күп кеше трактор алды (үзебезнең дә трактор бар), ватылса, әтиемә киләләр, чөнки аны күзен йомып та җыеп бирә, ул аны йөрәге белән тоя. «Ир-егеткә җитмеш төрле һөнәр дә аз», – ди безнең халык, бу әйтем нәкъ минем әтием турында.

Әйе, без – җир кешеләре. Без үзебезне җирсез, абзар тулы мал-туарсыз күз алдына да китерә алмыйбыз. Яз җитү белән, бакча эшләре башлана, анда эшләүне дә әтисез күз алдына китереп булмый. Ул һәр эшнең җаен белеп, уңайлы итеп эшли, яшелчәгә су сибү корылмасын да үзе хәстәрләде, җир йомшарта торганны да тимердән уңайлы итеп ясады.

Хатын-кызның күп вакыты газ плитәсе янында үтә. Безгә ул эшләрне дә җиңеләйтте. Өйгә суны да үзе кертте.

Ничек өлгерә ул барысына да? Иртән дүрттә торып эшкә китә, эше дә аяк өстендә үтә, кайткач, гантельләр белән шөгыльләнә, 18 яшьлек егетләр кебек. Әтием белән кибеткә кергәч, миңа кибетчеләр: «Сез бертуганнармы әллә?» – дигәч, миңа уңайсыз булып китә.

Әтием бездән беркайчан да бернәрсә дә жәлләми. Безнең кечкенәдән үз спорт бүлмәбез булды. Әти анда үзе җептән үреп канат, балаларымның буе кечкенә булмасын дип энемә дә, миңа да турник, гаиләбез белән утырып атынырга таган, энемә бокс грушасы эшләп куйды.

Ул хезмәт хакы алып кайткан көн бездә – бәйрәм. Ул сумка тулы тәм-томнар алып кайта, һәркайсыбызның нәрсә яратканын белә.

Безнең бәйрәмнәр дә, гаилә белән тыйнак кына булса да, бик күңелле үтә. Табын әзерләгәндә, бар кешенең үз өлеше кирә. Миңа иң ошаганы – барыбызның бергә пилмән бөгүе. Күпме генә тырышсак та, әтием кебек матур итеп пилмән бөгә алганыбыз юк әле.

Хәзерге вакытта мин Казанда укыйм, әти мине һәр атнаны эштән арып кайтуына карамастан, төн йокыларын йокламыйча озатып куя, каршы ала. «Кызым, тәмле чишмә сулары эчсен», – дип, суларга кадәр алып килә.

Алар әнием белән шундый пар килгәннәр. Әнием китапханәдә эшли. Әле дә хәтеремдә, без кечкенә чакта, барлык авыл яшьләре кичке тугыздан соң безгә килеп, әнием аларга спектакльләр өйрәтә иде. Шау-гөр килеп олы якка кереп утыралар, ә әтием бүлмәдән тыныч кына чыгып китә. Әнием актив булгач, гел төрле эшләрдән кайтып керми. Мәҗлесләрдә, туйларда әнием матур итеп җырлый, бии. Әтием эчмәгәч, барысын да тыныч кына кабул итә. Мин сезне бик яратам, кадерлеләрем.

Әтием белән бик горурланам, ул – гаиләбезнең ныклы тераге, минем иң якын киңәшчем, булышчым.

Мин питарда тавышларыннан бик куркам, алар миңа кинолардагы сугышны, бомба тавышларын хәтерләтә. Тыныч, мул илдә яшәсәк иде. Янда терәк, һәрвакыт ярдәмгә килүче ышанычлы, иң кадерле кешеләребез, әти-әниләребез булса иде. Һәр кешенең дә әтисе минем әтием кебек булсын.

Йолдыз ӘХМӘДИЕВА,
Биектау районы,
Сая авылы.

Мәхәббәте саклап йөрткән

Әтием Хәлил Хәкимулла улы 1918 елда Биектау районының Юртыш авылында бик көтеп алынган бала булып туган. Дәү әниләрнең аңа кадәр туган өч баласы озак яшәмичә үк үлгән.

12 яшендә ятим булып, апалары тәрбиясендә калып, шул ук елны колхозда җир сукалый башлый. Хезмәт кенәгәсендә дә шулай язылган. Ул хезмәтеннән ямь табып, акыл белән яши торган гадел кеше иде. Хәрәмләшүне җаны сөймәде, ялкау-ялганчыларны хөрмәт итмәде, үзе дә икейөзле булмады. Шушы гадәтләре миңа да күчкән. Мин дә гаделлек көрәшчесе.

1941 елда сугыш башлангач, әтине хәрби комиссариатка чакыралар. Ялгыз сеңлесе бар икәнен әйткәч, кайтарып җибәрәләр. Ләкин 1942 елның 13 февралендә фронтка озатылып, апрельдә хәрби ант кабул итә. 1942 елның 15 маеннан 709нчы укчы полк составында сугышларда катнашкан. Иң авыр сугышлар Калининград шәһәрен алганда булган. Бу шәһәрне алуга багышлап бирелгән медале дә бар. 1943 елның 3 сентябрендә уң аягы яралана, контузия ала. Аягындагы мина кыйпылчыгы үлгәнче сакланып калды, хирурглар урыныннан кузгатырга кушмадылар.

1945 елны сугыш тәмамланганнан соң, аларны дивизияләре белән Байкал арты фронтына, япон сугышына озаталар. Анда булган сугышларны искә алганда гел елый иде әтием. Медальләре дә күп иде. 1946 елның 28 октябрендә демобилизацияләнгән әти утырган поезд Казанга нәкъ бер ай дигәндә кайтып җитә. Казан вокзалында аларны җыелган халык каршы ала. Сафка тезеп, җиңү белән котлыйлар. Әтине Казанда калырга кыстыйлар, ул риза булмый, авылга кайта. Әтием өчен бу иң бәхетле көннәрнең берсе була.

Алар авылдагы яраткан кызы Хәдия белән хат алышып торалар. Әтиемнең көтеп алган Хәдия – безнең әниебез белән 1947 елны өйләнешәләр. Әти-әни канаты астында без – дүрт бала, бик бәхетле булып үстек. Мәктәптә белемне укытучы Әминә апа Усманова өйрәтсә, тәрбия һәм эш сөючәнлек гадәтләрен әтиебез өйрәтте. Хәмерне авызына да алып карамады, тәмәке тартмады. Ул төпле, нигезле акыл иясе иде.

Авылда торгач, хайван асрамый булмый. Сыер, сарык, каз-үрдәкләрне күп итеп асраганга, иткә, сөткә, майга аптырамадык. Әтиебез каядыр барып, үзебезнең сарык йонынннан итекләр бастырып алып кайта иде. Безне эшкә өйрәтеп, «тәртипле булыгыз» дип тәрбияләде. Бик сагындыра әти. Ул 87 яшендә, озак авырып ятмыйча гына, вафат булды.

Өч ир туганым да акыллы, тәртипле, эш сөючән, хөрмәткә лаек. Олы абыем Фәрит, хәрби диңгез флотында су асты көймәсендә хезмәт итеп, лаеклы ялга чыкты. Ул һәр елның җәендә ялга кайтып, әти-әниләргә булыша иде. ДАИ системасында эшләүче энем Фидаил 44 яшендә вафат булды. Полиция системасында эшләгән энебез Фәрук подполковник дәрәҗәсендә, лаеклы ялда.

Фирадия ХӘЙРУЛЛИНА,
Казан шәһәре.

Кардиолог Альберт Галявич:
«Һәркем үзе җаваплы»

Россия Президенты Владимир Путин тәкъдиме белән, 2015 ел – Йөрәк-кан тамырлары авыруларына каршы көрәш елы дип игълан ителгән иде. Узган ел да Татарстанда кан әйләнеше системасы авыруларын профилактикалауны пропагандалау буенча шактый эшләр дәвам иттерелде. Россия Сәламәтлек саклау министрлыгының баш белгеч-кардиологы Ирина Чазова сүзләренә караганда, Россиядә әлеге авырулардан үлүчеләр саны кимегән. Илдәге уртача күрсәткечләр белән чагыштырганда, Татарстанда бу саннар азрак та әле. 100 мең кешегә 601 очрак туры килә. Ә менә АКШта һәм Европада бу күрсәткечләр – 100 меңгә 250-300 очрак.

СӘЛАМӘТ ЙӨРӘККӘ БИШ АДЫМ

Шикәр дәрәҗәсен тикшертергә. Ул нормада 3,3–5,5 ммоль/л булырга тиеш.

Артериаль кан басымын тикшерергә. Дәваланганда артериаль кан басымын кимендә 140/90 дәрәҗәсенә җиткерергә кирәк, шикәр диабеты һәм йөрәк-кан тамырлары системасы ягыннан өзлегүләр мөмкинлеге югары булганда, кан басымы – 130/85, яшьләрдә 120/80 нормаль санала.

Тән авырлыгының индексын белергә. Моның өчен авырлыкны буйның квадратына бүләргә кирәк. Мәсәлән, авырлык 60 кг, буй 165 см булганда, болай эшләргә: 60: (1.65x 1.65) = 22. Авырлык нормасы – 18-25. Килеп чыккан сан 25тән күп булса, артык авырлык бар, 28дән дә артса, симерү дигән сүз. Корсак үсүе дә зыянлы. Ир-атның бил әйләнәсе 104 см дан, хатын-кызныкы 94 см дан артык икән, йөрәк-кан тамыры авырулары куркынычы арта.

Эштән соң яки иртән 40 минут (10 мең адым) **җәяү йөрергә.**

Холестерин дәрәҗәсен белергә. Ул 5,5 ммольдан да артык булырга тиеш түгел.

Күрсәткечләр яхшы якка үзгәрсә дә, Россиядә йөрәк-кан тамырлары авырулары, үлемгә китерә торган фактор буларак, беренче урында кала бирә. Елына әлеге авырулардан 1 млн 300 мең кеше вафат була. Шулар арасында инфаркт һәм инсульт – лидерлар. Тикшеренүләр кешедә бер яки берничә фактор (тәмәке тарту, югары кан басымы, шикәр авыруы, холестерин дәрәҗәсе арту һәм симерү) булган очракта, йөрәк-кан тамырлары авыруыннан үлү куркынычы артуын дәлилләгән. Әгәр саннарда карасак, мәсәлән, тәмәке тартучыларда йөрәк-кан тамырлары авыруыннан үлү куркынычы – 17, кан басымы югары булганда – 23, холестерин дәрәҗәсе югары булганда – 26, ә шикәр авыруыннан җәфаланучылар өчен 30 процентка кадәр арта.

Берничә көн элек Казанда «Сезнең сәламәтлегегез – Россиянең киләчәге» милли проекты кысаларында, Йөрәк-кан тамырлары авыруларына каршы көрәш көне үтте. Аның максаты – әлеге авыруларны мөмкин кадәр алданрак ачыклау һәм халыкның үз сәламәтлегенә игътибарын арттыру. Аерым алганда, әлеге проект дислипидемия, ягъни матдәләр алмашы бозылу нәтиҗәсендә кандагы холестерин дәрәҗәсе арту проблемасына юнәлтелгән. Әгәр статистика мәгълүматларына карасак, Россия халкының 50 процентттан артыгында холестеринның гомуми дәрәҗәсе нормадан югарырак, шул ук вакытта аларның 80 проценты үзләренең холестерин дәрәҗәсен белми. Шуңа күрә конференциядә әлеге проблемалар турында Казан дәүләт медицина университетының кардиология кафедрасы мөдире, Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгының белгеч-кардиологы һәм Россия кардиология җәмгыяте вице-президенты Альберт Галявич аеруча ачынып сөйләде.

– Йөрәк-кан тамырлары авыруларының нигезендә (70 процент очракта) сәламәт булмаган яшәү рәвеше тора. Нибары 30 процент очракта гына авырулар геннардан килә. Дөрес ашамыйбыз, дөрес эчмибез, начар йокլыйбыз, тоз күп кулланабыз, аз хәрәкәтләнәбез, телефон, компьютер каршында күп утырабыз, юк-барга борчылабыз. Бу проблемалар беренче урында тора. Моңа кадәр дә булган, тагын 10-15 ел шулай булачак әле. Татарстанлылар майлы ризык ашарга ярата, аның каравы җиләк-җимеш һәм яшелчә өстәлдә сирәк. Ә аларны көнгә 500 грамм кулланырга кирәк. Кардиологиядә иң авыры – кешедә үз сәламәтлегенә карата җаваплылык хисе тәрбияләү. Ни өчендер алар еллар дәвамында җыелып килгән авыруларны бик тиз генә дәвалап була торган тылсымлы таякчык бар дип уйлый. Һәр кеше беренче чиратта үз сәламәтлеген үзе кайгыртырга тиеш. Татарстанда никадәр спорт корылмасы бар. Аларны ярышлардан ярышларга гына файдаланырга кирәкми, спорт белән даими шөгыльләнсәк иде, – диде ул.

Кан тамырларының дошманнары	Кан тамырларының дуслары
